МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.11.2019 г.Казань № 1030

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 12 декабрендә 5989 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 419 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 419 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 16 маендагы 261 номерлы, 2018 елның 11 июлендәге 532 номерлы, 2019 елның 8 маендагы 341 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына, аны яңа редакциядә бәян итеп (кушымтада бирелә), үзгәрешләр кертергә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 25 июлендәге 592 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 14 ноябрендәге 1030 номерлы боерыгы редакциясендә) расланды

# ГРАЖДАННАРГА ТУРЫ КИЛӘ ТОРГАН ЭШ ЭЗЛӘҮДӘ, Ә ЭШ БИРҮЧЕЛӘРГӘ КИРӘКЛЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕ САЙЛАУДА БУЛЫШЛЫК ИТҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮНЕҢ АДМИНИСТРАТИВ РЕГЛАМЕНТЫ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – хезмәт) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Гариза бирүчеләр булып:

- үзләренә туры килә торган эш эзләү максаты белән теркәлгән гражданнар (алга таба – гариза бирүче (гражданин));

- эшкә алучы затлар яки аларның вәкаләтле вәкилләре (алга таба – гариза бирүче (эшкә алучы зат) тора.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Халыкның мәшгульлек үзәге урнашкан урын, аның эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган.

1.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнарның (учреждениеләрнең) атамалары турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының mtsz.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырылган. Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тотучы вазыйфаи затлар турында мәгълүмат әлеге Регламентның 4 номерлы кушымтасында китерелә.

1.3.3. Халыкның мәшгульлек үзәкләре, шимбә, якшәмбе һәм эшләми торган

бәйрәм көннәреннән тыш, көн саен эшли. Эш сәгатьләре Халыкның мәшгульлек үзәгенең эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләренә туры китереп билгеләнде.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы – шимбә, якшәмбе һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш, көн саен, халыкның мәшгульлек үзәгенең эш сәгатьләрендә.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат язылган, халыкның мәшгульлек үзәгендә гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнаштырылган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.3, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә (алга таба – Интернет челтәре):

Министрлыкның http://www.mtsz.tatarstan.ru, халыкның мәшгульлек үзәгенең рәсми сайтында;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (алга таба – Татарстан Республикасы порталы) (http://www.uslugi.tatarstan.ru);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал);

3) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләргә (алга таба – КФҮ) һәм (яисә) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урынына (алга таба – читтәге эш урыны) мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка, халыкның мәшгульлек үзәгенә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

5) халыкның мәшгульлек үзәгенә, Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә) (электрон почта адресы: mtsz@tatar.ru).

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләр нигезендә күрсәтелә:

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 1, 3 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы («Ведомости Съезда народных депутатов РСФСР и Верховного Совета РСФСР», 1991, № 18, 565 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – Халык мәшгульлеге турында закон);

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4563 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә чит ил инвестицияләре турында» 1999 елның 9 июлендәге 160-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1999, № 28, 3493 статья (кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып)(алга таба – 1999 елның 9 июлендәге 160-ФЗ номерлы федераль закон);

«Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 30, 3032 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3451 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон);

«Дәүләт һәм муниципаль хөзмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 статья) (алга таба – 601 номерлы указ);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җәмәгать эшләрен оештыру турында нигезләмә раслау хакында» 1997 елның 14 июлендәге 875 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1997, № 29, 3533 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт функцияләрен үтәүнең административ регламентларын һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау турында» 2011 елның 16 маендагы 373 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 22, 3169 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр һәм федераль башкарма хакимият органнары, бюджетка карамаган дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасында үзара хезмәттәшлек итү турында» 2011 елның 27 сентябрендәге 797 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 40, 5559 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Туры килә торган эш эзләү максатларында гражданнарны теркәүгә алу, эшсез гражданнарны теркәүгә алу тәртибе һәм туры килә торган эш эзләүгә карата таләпләр турында» 2012 елның 07 сентябрендәге 891 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 38, 5103 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 2012 елның 7 сентябрендәге 981 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 7 сентябрендәге 891 номерлы карары белән расланган кагыйдәләр);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 13 ноябрендәге 524н номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга

туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандарты (Российская газета, 2013, 30 гыйнвар, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып)(алга таба – 524н номерлы федераль стандарт);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Мәшгульлек хезмәте органнары һәм медик-социаль экспертиза буенча федераль учреждениеләр арасында белешмәләр алмашу тәртибен, формасын һәм срокларын раслау турында» 2015 елның 16 ноябрендәге 872н номерлы боерыгы («Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене», №5, 01.02.2016);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Медик-социаль экспертиза буенча дәүләт учреждениеләреннән бирелә торган инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм аларның формаларын раслау турында» 2017 елның 13 июнендәге 486н номерлы боерыгы (алга таба – 486н номерлы боерык) (Хокукый мәгълүмат тупланган рәсми интернет-портал (www.pravo.gov.ru), 2017, 1 август, басылып чыгу номеры: 0001201708010058);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкны эшкә урнаштыруга булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучының шәхси эш бланклары формаларын раслау турында» 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүмат тупланган рәсми интернет-портал (www.pravo.gov.ru), 2019, 19 март, басылып чыгу номеры: 0001201903190024) (алга таба – 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 2007, № 33, 1178 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган тәртип).

1.9. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәре яки муниципаль районы (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

- техник хата дәүләт хезмәтен күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтеннән файдалану турында гариза дигәндә дәүләт хезмәтеннән файдалану турында рәсми мөрәҗәгать аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәтне яки таләпне билгеләгән норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы | Гражданнарга туры килә торган эш, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү | Халык мәшгульлеге турында законның $7^{1-1}$ статьясының 1 пунктындагы 8 пунктчасы |
| 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы Халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениесе (халыкның мәшгульлек үзәге).<br>Халыкның мәшгульлек үзәге Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлеге территориясендә дәүләт хезмәте күрсәтелүен гамәлгә ашыра.<br>Дәүләт хезмәтенең бер (халык мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы затлар регистрына белешмәләр кертүгә бәйле булмаган) өлешен халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан килешү нигезендә җәлеп ителә торган, шул исәптән социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар – Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тиешле хезмәтләрне күрсәтү хокукына ия булган иҗтимагый файдалы хезмәтләрне башкаручылар тарафыннан күрсәтү рөхсәт ителә | Халык мәшгульлеге турында законның $7^{1-1}$ статьясының 1 пунктындагы 8 пунктчасы<br>524н номерлы федераль стандартның $11^1$ пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:<br>1. Гариза бирүчегә (гражданинга) 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык белән расланган форма буенча эшкә юллама-яисә эш вариантлары исемлеген бирү, яки халыкны эш белән тәэмин | 524н номерлы федераль стандартның 19 пункты<br>2019 елның 19 февралендәге |

| | | |
|---|---|---|
| | итү өлкәсендә башка төрле дәүләт хезмәтен күрсәтү турында тәкъдим итү, яки хатын-кызларга бала карау ялында булган вакытта балага өч яшь тулганчы халыкның мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем алырга тәкъдим итү. | 90н номерлы боерык |
| | Дәүләт хезмәтен күрсәтү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 7 сентябрендәге 891 номерлы карарында каралган очракларда гариза бирүче (гражданин) теркәлү исәбеннән төшерелүгә бәйле рәвештә туктатыла. | 524н номерлы федераль стандартның 20 пункты |
| | 2. Гариза бирүчегә (эшкә алучыга) кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алу өчен граждан кандидатуралары исемлеген бирү (җибәрү). | 524н номерлы федераль стандартның 25 пункты |
| | Гариза бирүчегә (эшкә алучыга) дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге очракларда туктатыла:<br>- халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча тиешле буш эш урыннарының (вакантлы вазыйфаларның) булмавы аркасында;<br>- эшкә алучы заттан тиешле буш эш урыннарын (вакантлы вазыйфаларны) мөстәкыйль биләү турында белешмәләр алганнан соң;<br>- эшкә алучы зат халыкның мәшгульлек үзәге беләнхезмәттәшлек итүдән баш тарткан очракта | 524н номерлы федераль стандартның 26 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга | Халыкның мәшгульлек үзәгенә беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән гариза бирүчегә (гражданинга, эшкә алучы затка) дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь рөхсәт ителгән вакыты 20 минуттан артмаска тиеш. | 524н номерлы федераль стандартның 17, 23 пунктлары |
| | Гариза бирүче (гражданин, эшкә алучы зат) алга таба тагын мөрәҗәгать иткән очракларда дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь рөхсәт ителгән вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. | 524н номерлы федераль стандартның 18, 24 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору Россия Федерациясе законнарында каралмаган | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, | 1. Халыкның мәшгульлек үзәгенә беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән гариза бирүчегә (гражданинга) дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документлар булып түбәндәгеләр тора:<br><br>- гариза бирүчедән (гражданиннан) 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык белән расланган форма нигезендә туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәтеннән файдалану турында гариза;<br>- гариза бирүченең Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алмаштыра торган документ (Россия Федерациясе гражданины өчен); | <br><br><br>524н номерлы федераль стандартның 5 пункты, 13 пункты;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 7 сентябрендәге 891 номерлы карары белән расланган |

| | | |
|---|---|---|
| гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | - чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклый торган документлар (чит ил гражданнары өчен);<br>- шәхес таныклый торган документлар (гражданлыгы булмаган затлар өчен).<br>Инвалидлар категориясенә караган гражданнар өчен өстәмә рәвештә билгеләнгән тәртиптә 21 бирелгән инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасы (алга таба – ИПРА) яки ИПРАдан бирелгән өземтә булуы таләп ителә (әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган очраклардан тыш).<br><br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бирүче (гражданин), шул исәптән, түбәндәге документларны да тапшыра ала:<br>- хезмәт кенәгәсе яки аны алмаштыра торган документ, шулай ук хезмәт килешүләре һәм хезмәт контрактлары;<br>- белем турында документлар, белем турында һәм квалификация турында документлар, квалификация турында документлар, белем алу турында документлар, фәнни дәрәҗәләр һәм фәнни исемнәр турында документлар;<br>- соңгы эш урыны буенча соңгы 3 ай өчен уртача хезмәт хакы турында белешмә;<br>- Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә гариза бирүченең (гражданинның) хезмәт эшчәнлеген яки башка төрле эшчәнлекне туктатуын раслый торган документлар (гражданлык-хокукый характердагы килешү, шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлекне туктату турында документ, нотариус вәкаләтләрен туктату турында документ, адвокат статусын туктату турында документ);<br>- гражданинны (гариза бирүчене) туры килә торган эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган, Халык мәшгульлеге турындагы | кагыйдәләренең 3 пункты; 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 13 нче номерлы кушымта<br><br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 7 сентябрендәге 891 номерлы карары белән расланган Туры килә торган эш-эзләү максатларында гражданнарны теркәүгә алу кагыйдәләренең 4 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | законның 5 статьясында каралган затлар категориясенә кертүне раслый торган документлар (инвалидның ничәнче төркемгә керүен күрсәтеп, инвалидлык билгеләнү очрагын раслый торган белешмә; иректән мәхрүм итү урыныннан азат ителү турында белешмә; федераль миграция хезмәте органнары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелгән, гражданинны качак яки мәҗбүри күченүче дип тануны раслый торган документ; Чернобыль һәм башка радиация һәлакәтләре һәм катастрофалары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданин таныклыгы; хәрби билет, эштән азат ителү нигезен күрсәтеп, азат ителү сәбәпләрен күрсәтеп, хәрби хезмәттән азат ителү турындагы боерыктан өземтә, никахлашу таныклыгы, хәрби частьтан белешмә; бала туу турында таныклык, аерылышу турында таныклык, ирнең (хатынның) вафат булуы турында таныклык, балага инвалидлык билгеләнү очрагын раслый торган таныклык, күп балалы гаилә таныклыгы, гражданинның бердәнбер ата-ана булып торуын раслый торган документ һәм балигъ булмаган балаларны, инвалид балаларны уллыкка алган затлар, опекуннар (попечительләр), тәрбиягә алган ата-аналар тарафыннан тапшырылырга мөмкин булган башка документлар). | |
| | Алга таба янә мөрәҗәгать иткәндә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бирүче (гражданин) түбәндәгеләрне күрсәтә:<br>- Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алмаштыра торган документ (Россия Федерациясе гражданины өчен);<br>- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклый торган документлар (чит ил гражданнары өчен);<br>- шәхес таныклый торган документлар (гражданлыгы булмаган затлар өчен);<br>- хезмәт кенәгәсе (билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнар өчен). | 524н номерлы федераль стандартның 16 пунктындагы 1 пунктчасы |

| | | |
|---|---|---|
| | Чит телдә төзелгән документлар рус теленә тәрҗемә ителергә тиеш. Тәрҗемәнең дөреслеге һәм тәрҗемәче имзасының чын булуы нотариус тарафыннан таныкланган булырга тиеш. | |
| | 2. Халыкның мәшгульлек үзәгенә беренче мәртәбә мөрәҗәгать иткән гариза бирүчегә (эшкә алучы затка) дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документлар:<br>- эшкә алучы заттан 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык белән расланган форма буенча кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза;<br>- 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык белән расланган форма буенча тутырылган «Хезмәткәрләргә ихтыяҗ, буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) булуы турында мәгълүматлар» бланкы (алга таба – Хезмәткәрләргә ихтыяҗ турында мәгълүматлар);<br>- Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алмаштыра торган документ (эшкә алучы затлар – Россия Федерациясе гражданлыгына ия булган физик затлар өчен);<br>- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклый торган документлар (эшкә алучы затлар – чит ил гражданлыгына ия булган физик затлар өчен);<br>- шәхесне таныклый торган документлар (эшкә алучы затлар – гражданлыгы булмаган физик затлар өчен). | 524н номерлы федераль стандартның 5 пункты, 14 пункты |
| | Алга таба янә мөрәҗәгать иткәндә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бирүче (эш бирүче) Хезмәткәрләргә булган ихтыяҗ турында белешмә күрсәтә (җибәрә).<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану турындагы гариза кәгазен гариза бирүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә | 524н номерлы федераль стандартның 22 пунктындагы 1 пунктчасы |

| | | |
|---|---|---|
| | алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы халыкның мәшгульлек үзәге рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Порталында урнаштырылган.<br>Гариза бирүчеләр өчен гариза бирү ысулын сайлау мөмкинлеге тудырыла: халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, почта аша, электрон почтаны да кертеп, факсимиль элемтә ярдәмендә яисә гади электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында, шул исәптән Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып, яисә гаризаны КФҮ, читтәге эш урыны аша тапшыру юлы белән | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул | Ведомствоара хезмәттәшлек итү каналлары аша түбәндәгеләрне үз эченә алган документлар алына:<br><br>- организмының бозылган функцияләрен һәм яшәеш эшчәнлегендәге чикләмәләрне исәпкә алып, инвалидның киңәш итеслә торган хезмәт һәм профессиональ эшчәнлеге төрләрен сайлау өчен белешмәләр (ИПРАдан өземтә) (Күрсәтелгән белешмәләр, 486н номерлы боерыкка 1 нче номерлы кушымтаның 14 пунктының «д» пунктчасы нигезендә, медик-социаль экспертиза үткәрә торган федераль учреждение тарафыннан мөстәкыйль җибәрелмәгән очракта соратыла. ИПРА өземтәдә организмның бозылган функцияләрен һәм яшәеш эшчәнлегендәге чикләмәләрне исәпкә алып, инвалидның киңәш итеслә торган хезмәт һәм профессиональ эшчәнлеге төрләрен сайлау өчен белешмәләр булмаган очракта яки мәшгульлек хезмәте органнарының ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасыннан файдалану мөмкинлеге булмаганда, инвалидлар категориясенә караучы гражданнар ИПРА тапшыра);<br><br>- юридик затны (шәхси эшкуарны, крестьян (фермер) хуҗалыгын) | 524н номерлы федераль стандартның 13 пункты<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>1999 елның 9 июлендәге |

| | | |
|---|---|---|
| исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | дәүләт теркәвенә алу турында, белешмәләрне Юридик затларның (Шәхси эшкуарларның) бердәм дәүләт реестрына кертү турында белешмәләр (алга таба – дәүләт теркәве турында таныклык);<br>- чит ил юридик затларының аккредитацияләнгән филиаллары; вәкиллекләрен дәүләт реестрына тиешле язуны кертү турында белешмәләр;<br>- аерым шәхси счетның иминият номеры.<br><br>Гариза бирүче (эшкә алучы зат) дәүләт теркәве турындагы таныклык күчермәсен (аккредитация һәм РФ Юстиция министрлыгы каршындагы Дәүләт теркәвенә алу палатасы дәүләт реестрына кертү турында таныклык – чит ил юридик затлары өчен) яки нотариаль тәртиптә таныкланган күчермәсен тапшырырга (җибәрергә) хокуклы, мөмкинлек булганда – электрон формада.<br>Гариза бирүченең (эш бирүченең) юридик затны (шәхси эшкуарны) юридик затны яки шәхси эшкуарны (крестьян (фермер) хуҗалыгын) дәүләт теркәвенә алу буенча Юридик затларның (Шәхси эшкуарларның) бердәм регистрында дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен яки аның нотариаль тәртиптә таныкланган күчермәсен тапшырмавы (җибәрмәве) гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Гариза бирүче (гражданин) шәхси (персональләштерелгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында да теркәлүне раслый торган документ тапшырырга хокуклы.<br>Гариза бирүче (гражданин) тарафыннан шәхси (персональләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ тапшырмау, шул исәптән электрон документ формасында да, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый. | федераль законның 4 статьясындагы 3 өлеше 160-ФЗ номерлы;<br><br>524н номерлы федераль стандартның 14 пункты<br><br>524н номерлы федераль стандартның 13 пункты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтелгән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтә торган дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны һәм мәгълүматларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | | |
| 2.7. Дәүләт | Дәүләт хезмәте күрсәтүгә документлар кабул итүдән баш тарту | | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:<br><br>1. Гариза бирүченең (гражданинның, эшкә алучы затның) тиешенчә рәсмиләштерелмәгән документларны тапшыруы (гариза тексты укылышлы түгел; гариза һәм шул исәптән электрон документ рәвешендә җибәрелгәне дә шәхси яисә электрон имза белән таныкланмаган; документларда язу бетерелгән, өстәп язылган, сүзләр сызылган урыннар һәм аларда килешенмәгән башка төзәтүләр булу).<br><br>2. Гариза бирүченең (гражданинның) ит телдә төзелгән, Россия Федерациясе дәүләт теленә тәрҗемә ителгән документларны нотариус тарафыннан расламаган рәвештә тапшыруы | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br><br>Халыкның мәшгульлек үзәгенә беренче мәртәбә мөрәҗәгать иткән гариза бирүчегә (гражданинга) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләрнең тапшырылмавы тора:<br>- дәүләт хезмәтеннән файдалану турында гариза;<br>- Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алмаштыра торган документ (Россия Федерациясе гражданнары өчен);<br>- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклый торган документлар (чит ил гражданнары өчен);<br>- гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклый торган документлар (гражданлыгы булмаган затлар өчен);<br>ИПРА (инвалидлар категориясенә караучы гражданнар өчен). (ИПРАдан өземтәдә организмының бозылган функцияләрен һәм яшәеш эшчәнлегендәге чикләмәләрне исәпкә алып, инвалидның киңәш ителә торган хезмәт һәм профессиональ эшчәнлеге төрләрен | 524н номерлы федераль стандартның 5 пункты, 13 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | сайлау өчен белешмәләр булмаган очракта яки мәшгульлек хезмәте органнарының ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасыннан файдалану мөмкинлеге булмаган очракта). | |
| | Гариза бирүче (гражданин) алга таба янә мөрәҗәгать иткәндә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләрнең юклыгы тора:<br>- гражданинның шәхесен һәм гражданлыгын таныклый торган документларның (Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алмаштыра торган документ; чит ил гражданинының шәхесен һәм аның гражданлыгын таныклый торган документлар; гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклый торган документлар) булмавы;<br>- ИПРА яки ИПРАдан өземтә (инвалидлар категориясенә караучы гражданнар өчен) булмау;<br>- хезмәт кенәгәсенең (билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнар өчен) булмавы. | 524н номерлы федераль стандартның 16 пунктындагы 1 пунктчасы; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 7 сентябрендәге 891 номерлы карары белән расланган Эшсез гражданнарны теркәү кагыйдәләренең 15 пункты |
| | Халыкның мәшгульлек үзәгенә беренче мәртәбә мөрәҗәгать иткән гариза бирүчегә (эш бирүчегә) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр тора:<br>- дәүләт хезмәтеннән файдалану турында гаризаның булмавы; | 524н номерлы федераль стандартның 5 пункты, 14 пункты |
| | - Хезмәткәрләргә ихтыяҗ булуы турында белешмәләр булмавы;<br>- шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гражданинның шәхесен һәм гражданлыгын таныклый торган документларның яки аларны алмаштыра торган документларның булмавы (эш бирүчегә – физик зат өчен);<br>- гаризаның, гариза тапшыручы эш бирүче – юридик зат яки шәхси эшкуар исеменнән тапшырылуы очрагында, Юридик | 1999 елның 9 июлендәге 160-ФЗ номерлы федераль законның 4 статьясындагы 3 өлеше; |

| | | |
|---|---|---|
| | затларның (Шәхси эшкуарларның) бердәм дәүләт реестрында эш бирүчене дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләрнең булмавы;<br>- ведомствоара мөрәҗәгатькә эш бирүче турында мәгълүмат юклыгы хакында җавап алыну – резидент булмаган зат турында чит ил юридик затларының аккредитацияләнгән филиалларының, вәкиллекләренең дәүләт реестрында чит ил юридик затының филиалын яки вәкиллеген аккредитацияләү очрагын раслый торган белешмәләрнең булмавы турында җавап алыну.<br>Гариза бирүче (эш бирүче) алга таба янә мөрәҗәгать иткәндә, Хезмәткәрләргә ихтыяҗ булуы турында белешмәләрнең юклыгы дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезе булып тора. | |
| | Халыкның мәшгульлек үзәгенә алкоголь, наркотик яки агуландыргыч матдәләр куллану аркасында исерек хәлдә мөрәҗәгать итү, ялган мәгълүмат яки дөрес булмаган мәгълүматлар бирү, гариза бирүчегә (гражданинга) туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен, ә гариза бирүчегә (эш бирүчегә) яки аның вәкиленә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора. | 524н номерлы федераль стандартның 22 пунктындагы 1 пунктчасы |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | 524н номерлы федераль стандартның 12 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| күләме һәм алыну нигезләре | | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалар тарафыннан бирелә (бирелә) торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтеннән файдалану турында, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәттән файдалану турында гариза тапшырганда, мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсен алганда, чиратта торуның максималь вакыты | Гариза бирүче (гражданин, эш бирүче) халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхси мөрәҗәгать иткәндә дәүләт хезмәте чират тәртибендә күрсәтелә.<br>Чиратта тору вакыты 15 минуттан артып китәргә тиеш түгел.<br>Көне һәм вакыты алдан килештерелгән очракта, дәүләт хезмәтеннән файдалануны көтү вакыты 5 минуттан артмаска тиеш | 524н номерлы федераль стандартның 8 пункты;<br>601 номерлы указның 1 пункты |
| 2.13. Гариза бирүче дәүләт | Гариза тапшырылган көнне.<br>Гаризаны теркәү дигәндә халыкны эш белән тәэмин итү | Халык мәшгульлеге турында законның 16.1 статьясындагы |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтеннән файдалану турында, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәттән файдалану турында гариза, шул исәптән электрон формадагысын да тапшырганда, аны теркәү вакыты һәм тәртибе | өлкәсендә дәүләт хезмәтеннән файдаланучыларның (физик затларның, эш бирүчеләрнең) электрон регистрына, хисап язмасының теркәү номерын биреп, гариза бирүче (гражданинның, эш бирүченең) тапшырган документлардагы белешмәләрне кертү күз алдында тотыла.<br>Гариза бирүченең (гражданинның, эш бирүченең) мөрәҗәгате нигезендә гаризаны кабул итү көне һәм исәпкә алу язуының теркәлү номеры турында белешмәләр булган гариза күчермәсе бирелергә мөмкин | 2 пункты |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәтеннән файдалану турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен | Дәүләт хезмәтен күрсәтү бүлмәләре аерым керү юлы булган биналарның аскы катларында яки аерым тора торган биналарда булдырыла.<br>Хезмәт күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу мөмкинлеге тудырыла (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урынына керү һәм чыгу өзлексез токның автоном чыганаклары белән тиешле күрсәткечләр белән җиһазландырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарда күренә торган җирдә янгын сүндерү чараларының урнашу һәм килүчеләрне һәм халыкның мәшгульлек үзәге белгечләрен эвакуацияләү юллары | |

| | | |
|---|---|---|
| кирәкле документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана | схемасы урнаштырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннар тавыш белән мәгълүмат җиткерү һәм электрон хәбәр итү системалары белән җиһазландырыла.<br>Хезмәт күрсәтү залларында (мәгълүмат залларында) гражданнарга туры килә торган эш вариантларын мөстәкыйль сайлау мөмкинлеген бирә торган белешмә-мәгълүмат һәм эзләтү системаларын үз эченә алган санау һәм электрон техника (алга таба - ПЭСМ) чаралары урнаштырыла. Белешмә-мәгълүмат һәм эзләтү системалары белән эшләү кагыйдәләре, шулай ук санау һәм электрон техника чаралары эше өчен җаваплы халыкның мәшгульлек үзәге белгеченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы һәм эшләү урыны турында белешмәләр ПЭСМ урнашкан урыннан турыдан-туры якын җирдә мәгълүмат стендында урнаштырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннар документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла, гариза бланклары, хезмәткәрләргә ихтыяҗ турында белешмә бланклары, таратыла торган мәгълүмат материаллары белән тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарда килүчеләргә файдалану мөмкинлеге булган иҗтимагый файдалану урыннарын (бәдрәфләрне) һәм өске кием-салымны саклау урыннарын булдыру күздә тотыла.<br>Халыкның мәшгульлек үзәге белгеченең эш урыны сигнализация чаралары (стационар «хәвеф төймәсе» яки күчмә күпфункцияле брелок-коммуникатор) белән җиһазландырыла, фамилиясен, исемен, атасының исемен һәм вазыйфасын күрсәтеп, стенага элеп куела торган элмә такта яки өстәл табличкасы белән тәэмин ителә. | |

| | | |
|---|---|---|
| алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | Халыкның мәшгульлек үзәге белгеченә фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы күрсәтелгән шәхси күкрәк тамгасы (бейдж) бирелә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыт озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация | Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:<br>1. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү үрнәкләре турында мәгълүматның, хосусый яки гавами (телдән яки язмача) мәгълүмат бирү (шәхсән кабул иткәндә, телефон элемтәсе, электрон почта чараларыннан файдаланып, массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару, мәгълүмат материаллары (брошюралар, белешмәлекләр, буклетлар һ.б.) нәшер итү, Татарстан Республикасы Порталында мәгълүмат урнаштыру юлы белән) формасында, гариза бирүче (гражданин, эш бирүче) тарафыннан файдалана алырлык булуы.<br>2. Гариза бирүченең (гражданинның, эш бирүченең) дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәк булган гаризалар һәм башка документлар формасына, шул исәптән аларны күчереп алу һәм электрон рәвештә тутыру мөмкинлеге белән керә алуын тәэмин итү.<br>3. Дәүләт хезмәтеннән файдалану турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсен алганда чират көтү вакытын саклау.<br>4. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән телефон элемтәсеннән, электрон почтадан файдаланып, Бердәм портал һәм Татарстан Республикасы Порталы, | |

| | | |
|---|---|---|
| технологияләренн ән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ | күпфункцияле үзәк аша, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында.<br>5. Инвалидларга хезмәтләрдән башка затлар белән тигез дәрәҗәдә файдаланырга комачаулый торган каршылыкларны үтүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә халыкның мәшгульлек үзәкләрендә халык мәшгульлеге турында Россия Федерациясе законнарындагымәҗбүри таләпләрнең, әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлүе.<br>2. Дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын саклау.<br>3. Әлеге Регламентта билгеләнгән административ процедураларның эзлеклелеген саклау.<br>4. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә баш тартуларның нигезле булуы.<br>5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләсе буенча нигезле шикаятьләрнең булмавы.<br>Гариза бирүченең халыкның мәшгульлек үзәге белгечләре белән үзара элемтәгә керү саны:<br>дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>документларны почта аша җибәргәндә, шул исәптән электрон документ формасында – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Үзара хезмәттәшлек итү дәвамлылыгы әлеге Регламентта билгеләнә.<br>КФҮләрдә, КФҮләрнең читтәге эш урынында дәүләт хезмәте күрсәтелми.<br>Гариза бирүче КФҮ, КФҮ читтәге эш урынына мөрәҗәгать | |

| | | |
|---|---|---|
| номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гариза тапшыру (комплекслы мөрәҗәгать) юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә) яки файдалана алмау мөмкинлеге | иткәндә, гариза теркәлгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә халыкның мәшгульлек үзәге һәм КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибе - халыкның мәшгульлек үзәге һәм КФҮ арасында төзелә торган хезмәттәшлек турында килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлек итү тәртибе КФҮ эш регламенты белән җайга салына.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми. | 524н номерлы федераль стандартның 10 пункты |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча | Дәүләт хезмәтеннән файдалануга гариза тапшырудан тыш, дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелми.<br>Электрон документ формасындагы гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләрен кулланып җибәрелергә, шулай ук халыкның мәшгульлек үзәгенә гариза бирүче тарафыннан электрон мәгълүмат саклагычларда тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гаризага 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның | 524н номерлы федераль стандартның 27 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтелгән очракта) үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | $21^1$ һәм $21^2$ статьялары нигезендә гади электрон имза куелырга тиеш.<br>Халыкның мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар регистрында үзләре турында белешмәләр булган гариза бирүчеләргә телефон яки электрон элемтә чараларыннан файдаланып, 3 календарь көне эчендә халыкның мәшгульлек үзәгенә килү тәкъдиме белән, гариза бирүченең (гражданинның) һөнәри әзерлек дәрәҗәсе хезмәт функциясен үтәү (билгеле бер һөнәр (белгечлек), квалификация яки вазыйфа буенча эшләү) өчен эшкә алучы таләпләренә туры килү шарты белән, буш эш урыны (вакантлы вазыйфа) булуы турында эшкә алучыдан мәгълүматлар килүе турында мәгълүмат алу мөмкинлеге тудырыла. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакыты, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрнең читтәге эш урыннарында башкару үзенчәлекләре

3.1. Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә (гражданинга, эш бирүчегә) консультация бирү, гариза бирүчегә (гражданинга, эш бирүчегә) ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) беренче тапкыр мөрәҗәгать итүче гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә дәүләт хезмәте күрсәтү;

3) алга таба кабат мөрәҗәгать итүче гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә дәүләт хезмәте күрсәтү;

4) беренче тапкыр мөрәҗәгать итүче эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда дәүләт хезмәте күрсәтү;

5) алга таба кабат мөрәҗәгать итүче эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда дәүләт хезмәте күрсәтү;

6) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм җибәрү, белешмәләр алу;

7) гариза бирүчеләргә электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү;

8) техник хатаны (язу хатасын, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.2. Гариза бирүчегә (гражданинга, эш бирүчегә) консультация бирү, гариза бирүчегә (гражданинга, эш бирүчегә) ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә

Телдән мөрәҗәгать иткән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчегә (гражданинга, эш бирүчегә), шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләр бирә һәм гариза бирүчегә (гражданинга, эш бирүчегә), шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтә.

Гариза бирүче (гражданин, эш бирүче) мөрәҗәгатькә язмача җавап алырга теләгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчегә (гражданинга, эш бирүчегә), шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча язмача консультацияләр бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә консультация бирү, аңа ярдәм

күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

3.3. Беренче тапкыр мөрәҗәгать итүче гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә дәүләт хезмәте күрсәтү

3.3.1. Беренче тапкыр мөрәҗәгать итүче гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә түбәндәге административ гамәлләр башкарыла:

1) туры килә торган эш эзләү максатыннан теркәлгәндә, гариза бирүче (гражданин) тарафыннан күрсәтелгән документлар нигезендә халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрына кертелгән гариза бирүчеләр (гражданиннар) - физик затлар (алга таба - Физик затлар регистры) турында белешмәләргә анализ һәм халыкны эш белән тәэмин итү турындагы законнар нигезендә, түбәндәге белешмәләрнең булу яки булмавын исәпкә алып, гариза бирүче өчен туры килә торган эшне билгеләү:

һөнәрләре (белгечлекләре), вазыйфалары, эшчәнлек төрләре турында белешмә;

һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсе, эш тәҗрибәсе һәм күнекмәләре турында белешмә;

соңгы эш урыны буенча соңгы 3 ай өчен исәпләнгән уртача хезмәт хакы турында белешмә;

ИПРАда булган, тәкъдим ителә торган хезмәт характеры һәм шартлары турында белешмә;

2) гариза бирүчегә (гражданинга) түбәндәгеләр турында мәгълүмат бирү:

Халыкны эш белән тәэмин итү турында законның 4 статьясындагы нигезләмәләре;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 7 сентябрендәге 891 номерлы карары белән расланган туры килә торган эшне сайлап алуга карата таләпләр;

гариза бирүче (гражданин) туры килә торган эштән баш тарткан очракта хокукый нәтиҗәләр;

хезмәткә карата, хезмәт өлкәсендә мәҗбүри эшләтүне һәм дискриминацияне тыюга карата хокук билгели торган хезмәт законнарының нигезләмәләре;

3) халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрындагы (вакансияләр банкында һәм эш бирүчеләрдә) ирекле эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турындагы белешмәләрдән чыгып, гариза бирүчегә (гражданинга) туры килә торган эш сайлау;

4) гариза бирүче (гражданин) белән туры килә торган эш вариантларын килештерү;

5) эш бирүче белән гариза бирүче (гражданин) кандидатурасын килештерү;

6) гариза бирүчегә (гражданинга) эшкә 2 дән дә артык булмаган юллама рәсмиләштерү һәм бирү;

7) гариза бирүчегә (гражданинга) бирелгән юлламаны эш бирүче тамгасы белән эшкә бирү кирәклеге турында мәгълүмат җиткерү;

8) гариза бирүче (гражданин) туры килә торган эш вариантына риза булмаган очракта, баш тартуны рәсмиләштерү

9) гариза бирүчегә (гражданинга) туры килә торган эш вариантлары булмаган очракта түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

катнаш һөнәр (белгечлек) буенча эшкә юллама;

халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрындагы (вакансияләр банкында һәм эш бирүчеләрдә) хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар таләпләренә җавап бирә торган, алдан әзерләнүне таләп итә яки таләп итми торган вакытлыча характердагы эшне дә кертеп, эш бирүчеләргә мөстәкыйль бару өчен түләнә торган эш вариантлары;

халыкны эш белән тәэмин итү турында законның $7^{1-1}$ статьясында билгеләнгән халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

10) өч яшенә җиткәнче бала карау буенча отпускта булган хатын-кызларга, картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген дәвам итәргә омтылган гражданнарга халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча профессиональ укырга яки өстәмә һөнәри белем алырга тәкъдим итү;

11) гариза бирүчегә (гражданинга) аның ризалыгы белән түбәндәгеләрне рәсмиләштерү һәм бирү:

катнаш һөнәр (белгечлек) буенча эшкә юллама;

эш вариантлары исемлеге;

халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим итү;

халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча профессиональ укырга тәкъдим итү;

12) физик затлар регистрына административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү нәтиҗәләрен кертү.

3.3.2. Туры килә торган эш эзләү максатыннан теркәлгәндә, гариза бирүче (гражданин) тарафыннан күрсәтелгән документлар нигезендә физик затлар регистрына кертелгән гариза бирүче (гражданин) турында белешмәләргә анализ һәм халыкны эш белән тәэмин итү турында законнар нигезендә; түбәндәге белешмәләрнең булу яки булмавын исәпкә алып, гариза бирүче өчен туры килә торган эшне билгеләү:

һөнәрләре (белгечлекләре), вазыйфалары, эшчәнлек төрләре турында белешмә;

һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсе, эш тәҗрибәсе һәм күнекмәләре турында белешмә;

соңгы эш урыны буенча соңгы 3 ай өчен исәпләнгән уртача хезмәт хакы турында белешмә;

ИПРАда булган, тәкъдим ителә торган хезмәт характеры һәм шартлары турында белешмә.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә почта, шул исәптән электрон почта, факсимиль элемтә аша яки электрон документ формасында, шул исәптән Бердәм портал яки Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып, гариза килгән очракта, яки гариза КФҮ, читтәге эш урыны аша тапшырылганда, мәшгульлек

үзәге белгече гариза тапшырылган көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча, гариза бирүче (гражданин) белән аны шәхсән кабул итүнең көнен, вакытын килештерә, шулай ук әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны тапшыру кирәклеге турында хәбәр итә.

Шәхси кабул итү барышында халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең булу-булмавын тикшерә.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өнен нигезләр булган очракта, мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчегә (гражданинга) баш тарту өчен нигезләр булу турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кире кайтара.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта:

- гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәтеннән файдалану турында гариза (формасы 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыгы белән расланган) кабул итә (кирәк булган очракта тутыруда ярдәм итә);
- әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларның булу-булмавын тикшерә.

Гариза бирүче (гражданин) тарафыннан күрсәтелгән документлар нигезендә әлеге Регламентның 2.8 пунктында билгеләнгән сәбәпләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү яки аны күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту очрагында халыкның мәшгульлек үзәге белгече баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен аңлата, әлеге Регламентның 1 нче номерлы кушымтасына туры китерелгән формада 2 нөсхәдә язмача рәвештә баш тарту турында карар рәсмиләштерә, аның берсе халыкның мәшгульлек үзәгендә кала, икенчесе – гариза бирүчегә (гражданинга) бирелә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече физик затларның электрон регистрына гариза бирүче (гражданин) күрсәткән документлардагы белешмәләрне кертү юлы белән, хисап язмасының теркәү номерын биреп, гариза бирүчене (гражданинны) терки.

Гариза бирүченең (гражданинның) соравы буенча гаризаны кабул итү көне һәм хисап язмасының теркәү номеры турында белешмәләр булган гариза күчермәсе бирелергә мөмкин.

Үтәү вакыты: процедуралар 5 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (гражданинга) документларны кабул итүдән баш тарту турында язмача хәбәрнамә һәм гариза бирүчегә (гражданинга) кире кайтарылган документлар, туры килә торган эш эзләү максатыннан гариза бирүчене (гражданинны) теркәү исәбенә кую яисә халыкның мәшгульлек үзәгенең, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтүдән язмача баш тартуы.

3.3.3. Туры килә торган эш вариантларын сайлаганда гариза бирүчегә (гражданинга) хәбәр итү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчегә (гражданинга) телдән түбәндәгеләр турында хәбәр итә:

«туры килә торган һәм туры килми торган эш» төшенчәсен ачыклый торган, халыкны эш белән тәэмин итү турында законның 4 статьясы нигезләмәләре хакында;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 7 сентябрендәге 891 номерлы карары белән расланган туры килә торган эшне сайлап алуга карата таләпләр турында;

гариза бирүче (гражданин) туры килә торган эштән баш тарткан очракта хокукый нәтиҗәләр турында;

хезмәткә карата, хезмәт өлкәсендә мәҗбүри эшләтүне һәм дискриминацияне тыюга карата хокук билгели торган хезмәт законнарының нигезләмәләре турында;

туры килә торган эш вариантын сайлаганда, гаризада булган мәгълүматларның, аларны документлар нигезендә раслаган очракта, исәпкә алынуы турында.

Үтәү вакыты: процедура процедураны башлап җибәргәннән соң 2 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (гражданинга) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат бирү.

3.3.4. Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрындагы (вакансияләр банкындагы һәм эш бирүчеләрдәге) ирекле эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турындагы белешмәләрдән чыгып, гариза бирүчегә (гражданинга) туры килә торган эш сайлау

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрындагы (вакансияләр банкындагы һәм эш бирүчеләрдәге) ирекле эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турындагы белешмәләрдән чыгып, гариза бирүченең (гражданинның) һөнәрен (белгечлеген), вазыйфасын, эшчәнлек төрен, һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсен, эш тәҗрибәсен һәм күнекмәләрен, соңгы эш урыны буенча уртача хезмәт хакы күләмен, күрсәтелмәгән һәм мөмкин булган шартларны һәм хезмәт төрләрен, эш урынының транспорт килеп җитә торган урында урнашканлыгын, гариза бирүченең (гражданинның) эзли торган эшкә карата теләкләрен, шулай ук эш бирүченең хезмәт функциясе үтәлешенә һәм хезмәткәр кандидатурасына карата таләпләрен исәпкә алып, аңа туры килә торган эш сайлый.

Гариза бирүчеләргә (гражданнарга), физик затлар регистрында булган, эш бирүчедән алар өчен туры килә торган буш эш урыны һәм вакантлы вазыйфа булуы турында белешмәләр телдән (телефон аша) яки язмача (электрон документ формасы буенча) формада алынганда, 3 көн дәвамында эшкә юллама алу һәм рәсмиләштерү өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә барырга тәкъдим

итела.

Туры килә торган эшне сайлаганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

- бер үк төрле эш вариантын ике тапкыр тәкъдим итү, ә беренче тапкыр эш эзләүче, элек бер дә эшләмәгән һәм әле һөнәре (белгечлеге) дә булмаган гражданнарга һөнәри әзерлекнең бер үк вариантын ике тапкыр тәкъдим итү;

- эш урынының транспорт килеп җитә торган урында урнашуын, җәмәгать транспорты челтәрен үстерүне исәпкә алмыйча эш урыннарына җибәрү;

- гариза бирүчеләрнең (гражданнарның) ризалыгыннан башка яшәү урынын үзгәртү белән бәйле эш тәкъдим итү;

- хезмәтне саклау кагыйдәләренә һәм нормаларына туры килми торган эш, хезмәт шартлары тәкъдим итү;

- гариза бирүченең (гражданинның) соңгы эш урыны буенча соңгы 3 ай эчендә уртача хезмәт хакыннан түбәнрәк булган эш тәкъдим итү. Әлеге нигезләмә уртача хезмәт хакы Татарстан Республикасында билгеләнгән тәртиптә исәпләнгән эшкә сәләтле халыкның яшәү минимумы күләменнән артып киткән гариза бирүчеләргә (гражданнарга) кагылмый.

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрында (вакансияләр банкында һәм эш бирүчеләрдә) туры килә торган эш булганда халыкның мәшгульлек үзәге белгече иректе эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында мәгълүматны үз эченә алган исемлекне бастырып чыгара һәм аны гариза бирүчегә (гражданинга) тәкъдим итә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 2 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүче (гражданин) тарафыннан буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлекне алу.

3.3.5. Туры килә торган эш вариантларын гариза бирүче (гражданин) белән килештерү

Гариза бирүче (гражданин) халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим иткән исемлектән туры килә торган эш вариантларын сайлап ала һәм эш бирүчегә әңгәмәгә килү өчен үзенең ризалыгын (ризасызлыгын) белдерә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүченең (гражданинның) халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим иткән исемлектән үзенә туры килә торган эш вариантын сайлап алуы.

3.3.6. Эш бирүче белән гариза бирүче (гражданин) кандидатурасын килештерү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүче (гражданин) сайлап алган аңа туры килә торган эш вариантлары нигезендә телефон аша эш бирүче белән гариза бирүченең (гражданинның) әңгәмәгә юлламасын килештерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында гариза бирүчегә (гражданинга) Интернет челтәрен кулланып телефон яки видеоэлемтә аша әңгәмә уздыру мөмкинлеге булдырыла.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 2 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүче белән гариза бирүченең (гражданинның) әңгәмәгә юлламасын килештерү яисә Интернет челтәрен кулланып телефон яки видеоэлемтә аша әңгәмә уздыру.

3.3.7. Гариза бирүчегә (гражданинга) әңгәмәне узу өчен эшкә 2 дән дә артык булмаган юллама рәсмиләштерү һәм бирү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчегә (гражданинга) 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык белән расланган форма нигезендә бер үк вакытта эшкә 2 дән дә артык булмаган юллама бирә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (гражданинга) эшкә 2 дән дә артык булмаган юллама рәсмиләштерү һәм бирү.

3.3.8. Гариза бирүчегә (гражданинга) бирелгән юлламаны эш бирүче тамгасы белән эшкә бирү кирәклеге турында мәгълүмат җиткерү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчегә (гражданинга) юллама бирелгән көннән алып өч көн эчендә эшкә урнашу мәсьәләләре турында эш бирүче белән әңгәмә узу кирәклеге һәм эшкә бирелгән юлламаны әңгәмә нәтиҗәләре турында эш бирүче тамгасын куйдыртып кире халыкның мәшгульлек үзәгенә бирү кирәклеге турында хәбәр итә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (гражданинга) әңгәмәне узу вакыты һәм бирелгән юлламаны эш бирүче тамгасы белән эшкә бирү кирәклеге турында мәгълүмат җиткерү.

3.3.9. Гариза бирүче (гражданин) риза булмаган очракта туры килә торган эш вариантыннан баш тартуны рәсмиләштерү

Гариза бирүче (гражданин) туры килә торган эш варианты белән килешмәве турында язмача фикерен белдерә һәм баш тарту очрагын үзенең имзасы белән раслый.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүченең (гражданинның) туры килә торган эш вариантларыннан язмача баш тартуы.

3.3.10. Туры килә торган эш вариантлары булмаган очракта халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчегә (гражданинга) түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

- чиктәш һөнәр (белгечлек) буенча эшкә юллама;

- хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар таләпләренә җавап бирә торган, алдан әзерләнүне таләп итә яки таләп итми торган вакытлыча характердагы эшне дә кертеп, эш бирүчеләргә мөстәкыйль бару өчен түләнә торган эш вариантлары;

- халыкны эш белән тәэмин итү турында законның 71-1 статьясында

билгеләнгән халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт хезмәтләре күрсәтү.

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрында (вакансияләр банкында һәм эш бирүчеләрдә) чиктәш һөнәр (белгечлек) буенча буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече чиктәш һөнәр (вакантлы вазыйфалар) буенча буш эш урыннары (белгечлекләре) турында белешмәләр тупланган исемлекне бастырып чыгара һәм гариза бирүчегә (гражданинга) тәкъдим итә.

Гариза бирүче (гражданин) белән чиктәш һөнәр (белгечлек) буенча эш вариантларын килештерү һәм эш бирүче белән гариза бирүче (гражданин) кандидатурасын килештерү әлеге Регламентның 3.3.5-3.3.6 пунктларында каралган гамәлләр эзлеклелеге нигезендә гамәлгә ашырыла.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүченең (гражданинның) халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдим иткән исемлектән катнаш һөнәр (белгечлек) буенча эш вариантын сайлавы яисә гариза бирүченең (гражданинның), халыкны эш белән тәэмин итү турында законның $7^{1-1}$ статьясында билгеләнгән, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт хезмәтләре күрсәтү турындагы тәкъдим белән риза булуы.

3.3.11. Өч яшенә җиткәнче бала карау буенча отпускта булган хатын-кызларга, картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген дәвам итәргә омтылган гражданнарга халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча профессиональ укырга яки өстәмә һөнәри белем алырга тәкъдим итү

Туры килә торган эш булмаганда халыкның мәшгульлек үзәге белгече туры килә торган эш эзләүдә булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәтен күрсәткәндә өч яшенә җиткәнче бала карау буенча отпускта булган хатын-кызга, картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген дәвам итәргә омтылган гражданинга мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча профессиональ укырга яки өстәмә һөнәри белем алырга тәкъдим итә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: өч яшенә җиткәнче бала карау буенча отпускта булган хатын-кызның, картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген дәвам итәргә омтылган гражданинның мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча профессиональ уку яки өстәмә һөнәри белем алу вариантын сайлавы.

3.3.12. Гариза бирүчегә (гражданинга) аның ризалыгы белән түбәндәгеләрне рәсмиләштерү һәм бирү:

катнаш һөнәр (белгечлек) буенча эшкә юллама;

буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлек;

халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт

хезмәте күрсәтү турында тәкъдим итү;

халыкның мәшгульлек үзәге юлламасы буенча профессиональ укырга тәкъдим итү.

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрында (вакансияләр банкында һәм эш бирүчеләрдә) халыкның мәшгульлек үзәге белгече, вакытлыча характердагы эшне дә кертеп, түләүле эшнең теләсә нинди вариантын сайлый, эш бирүчеләргә мөстәкыйль рәвештә бару өчен эш вариантлары исемлеген бастырып чыгара һәм аны гариза бирүчегә (гражданинга) тәкъдим итә.

Гариза бирүчегә (гражданинга) аның ризалыгы белән катнаш һөнәр (белгечлек) буенча эшкә юллама рәсмиләштерү һәм бирү әлеге Регламентның 3.3.7 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүче (гражданин) халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдим белән риза булган очракта, мәшгульлек үзәге белгече:

- гариза бирүчегә (гражданинга) эш урыннары һәм эшләп уку урыннары ярминкәсен үткәрү көне, вакыты һәм кайда үтәчәге турында хәбәр итә;

- түләүле иҗтимагый эшләр үткәрүне оештыру буенча дәүләт хезмәтенең Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2013 елның 11 февралендәге 52н номерлы боерыгы белән расланган федераль дәүләт стандартында каралган административ процедураларны гамәлгә ашыра;

- беренче тапкыр эш эзләүче, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар арасыннан 18 яшьтән алып 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, укудан буш вакытта 14 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәтенең Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2013 елның 12 февралендәге 58н номерлы боерыгы белән расланган федераль дәүләт стандартында каралган административ процедураларны (гамәлләрне) гамәлгә ашыра;

- эшсез гражданнарга, башка җирлектә укытуны да кертеп, һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча дәүләт хезмәтенең Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 17 апрелендәге 262н номерлы боерыгы белән расланган федераль дәүләт стандартында каралган административ процедураларны (гамәлләрне) гамәлгә ашыра.

Үтәү вакыты: процедура әлеге Регламентның 3.3.10 пунктында яки 3.3.11 пунктында каралган процедураны тәмамлаганнан соң 2 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе:

гариза бирүчегә (гражданинга) 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыгы белән расланган форма буенча рәсмиләштерелгән катнаш һөнәр (белгечлек) буенча эшкә юллама рәсмиләштерү һәм бирү;

эш бирүчеләргә мөстәкыйль бару өчен, гариза бирүчегә (гражданинга) буш

эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлекне тәкъдим итү;

халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим;

халыкның мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем бирүне тәкъдим итү.

3.3.13. Физик затлар регистрына административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү нәтиҗәләрен кертү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече физик затлар регистрында түбәндәгеләрне терки:

- дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен (гариза бирүчегә (гражданинга) эшкә юллама бирү, буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлек бирү, туры килә торган эш вариантыннан баш тарту);

- эш белән тәэмин итүнең актив сәясәте чараларында катнашуга бару очрагын (гариза бирүчегә (гражданинга), шул исәптән өч яшенә җиткәнче бала карау буенча отпускта булган хатын-кызларга да, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим итү, халыкның мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы нигезендә һөнәри белем бирү буенча укуны тәкъдим итү).

Үтәү вакыты: процедура әлеге Регламентның 3.3.7, 3.3.9, 3.3.12 пунктларында каралган процедураларның берсе тәмамланганнан соң 1 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: физик затлар регистрында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә гариза бирүчегә (гражданинга) башка дәүләт хезмәтен, туры килә торган эш эзләүдә булышлык итү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен теркәү.

3.4. Алга таба кабат мөрәҗәгать итүче гариза бирүчеләргә (гражданнарга) туры килә торган эш эзләүдә булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү

3.4.1. Гариза бирүче (гражданин) алга таба кабат мөрәҗәгать иткәндә, туры килә торган эш эзләүдә ярдәм итү өлешендә дәүләт хезмәте түбәндәге административ гамәлләрне үз эченә ала:

1) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән, гариза бирүченең (гражданинның) алга таба кабат мөрәҗәгате вакытында күрсәтелергә тиешле документларның булу-булмавын тикшерү;

2) гариза бирүчегә (гражданинга) халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениесенә соңгы тапкыр барганда бирелгән эш вариантлары исемлеге нигезендә, эшкә бирелгән юлламага эш бирүче тарафыннан куелган тамга белән яисә гариза бирүченең (гражданинның) эш бирүчеләргә барып кайту нәтиҗәсе турындагы мәгълүматы белән танышу;

3) гариза бирүче (гражданин) тарафыннан өстәмә тапшырылган документлардагы белешмәләрне исәпкә алып, туры килә торган эш эзләү критерийларын һәм/яки башка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен ачыклау;

4) әлеге Регламентның 3.3.1 пунктындагы 3-12 пунктчаларында каралган административ процедураларны гамәлгә ашыру.

3.4.2. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның булу-булмавын тикшерү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

- әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән, гариза бирүченең (гражданинның) алга таба кабат мөрәҗәгате вакытында күрсәтелергә тиешле документларның булу-булмавын тикшерә;

- әлеге Регламентның 2.8 пункты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү яки аны күрсәтүдән баш турында карар кабул итә.

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту очрагында халыкның мәшгульлек үзәге белгече баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен аңлата, әлеге Регламентның 1 нче номерлы кушымтасына туры китерелгән формада 2 нөсхәдә язмача рәвештә баш тарту турында карар рәсмиләштерә, аның берсе халыкның мәшгульлек үзәгендә кала, икенчесе – гариза бирүчегә (гражданинга) бирелә.

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече агымдагы архивтан гариза бирүченең (гражданинның) шәхси мәгълүматларына туры килә торган, элек тутырылган хисап документлары бланкларын ала.

Үтәү вакыты: процедура 1 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү турында яисә халыкның мәшгульлек үзәгенең баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтүдән язмача баш тартуы турында карар.

3.4.3. Гариза бирүчегә (гражданинга) халыкның мәшгульлек үзәгенә соңгы тапкыр барганда бирелгән буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында мәгълүматлар тупланган исемлек нигезендә, эшкә бирелгән юлламага эш бирүче тарафыннан куелган тамга белән яисә гариза бирүченең (гражданинның) эш бирүчеләргә барып кайту нәтиҗәсе турындагы мәгълүматы белән танышу

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече эш бирүчеләр тарафыннан куелган тамгалы эшкә бирелгән юлламаны кабул итә яисә соңгы тапкыр барганда бирелгән исемлек нигезендә, гариза бирүчедән (гражданиннан) аның эш бирүчеләргә барып кайту нәтиҗәсен ачыклый.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 2 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (гражданинга) халыкның мәшгульлек үзәгенә соңгы тапкыр барганда бирелгән эш вариантлары тупланган исемлек нигезендә, эшкә бирелгән юлламага эш бирүче тарафыннан куелган тамга белән яисә гариза бирүченең (гражданинның) эш бирүчеләргә барып кайту нәтиҗәсе турындагы мәгълүматы белән танышу.

3.4.4. Гариза бирүче (гражданин) тарафыннан өстәмә тапшырылган документлардагы белешмәләрне, һәм/яки башка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен исәпкә алып, туры килә торган эш эзләү критерийларын ачыклау

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече, гариза бирүче (гражданин) тарафыннан өстәмә тапшырылган документлардагы белешмәләрне, һәм/яки башка дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен исәпкә алып, гариза бирүчедән

(гражданиннан) аңа туры килә торган эш вариантларын эзләү критерийларын ачыклый.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: туры килә торган эш эзләү критерийларын ачыклау.

3.4.5. Әлеге Регламентның 3.3.1 пунктындагы 3-12 пунктчаларында каралган административ процедураларны гамәлгә ашыру

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Регламентның 3.3.4-3.3.13 пунктларында билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге нигезендә:

- гариза бирүчегә (гражданинга) туры килә торган эш вариантын сайлап алуны гамәлгә ашыра;

- гариза бирүчегә (гражданинга) катнаш һөнәр (белгечлек) буенча эш вариантын сайлап алуны гамәлгә ашыра;

- халыкны эш белән тәэмин итү турында законның 71-1 статьясында билгеләнгән халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт хезмәтләрен күрсәтүне тәкъдим итә;

халыкның мәшгульлек хезмәте юлламасы нигезендә, гражданнарга, шул исәптән өч яшенә җиткәнче бала карау буенча отпускта булган хатын-кызларга, һөнәри әзерлек, яңадан әзерләү яки квалификация күтәрү гамәлләрен тәкъдим итә;

- физик затлар регистрында административ гамәлләрнең үтәлү нәтиҗәләрен терки.

Үтәү вакыты: процедура кабат мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе:

гариза бирүчегә (гражданинга) 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыгы белән расланган форма нигезендә эшкә юллама рәсмиләштерү һәм бирү;

гариза бирүчегә (гражданинга) 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыгы белән расланган форма нигезендә катнаш һөнәр (белгечлек) буенча эшкә юллама рәсмиләштерү һәм бирү;

эш бирүчеләргә мөстәкыйль бару өчен, гариза бирүчегә (гражданинга) буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлекне бирү;

халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим итү;

халыкның мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем бирүне тәкъдим итү.

3.5. Беренче тапкыр мөрәҗәгать итүче эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү

3.5.1. Беренче тапкыр мөрәҗәгать итүче гариза бирүчеләргә (эш бирүчеләргә) кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә түбәндәге административ гамәлләр башкарыла:

1) гариза бирүче (эш бирүче) турында һәм гариза бирүче (эш бирүче)

тарафыннан тапшырылган документларда хезмәткәрләргә ихтыяҗ булуы турындагы белешмәләрне анализлау;

2) гариза бирүчегә (эш бирүчегә) түбәндәгеләр турында мәгълүмат бирү:

халыкны эш белән тәэмин итүдә катнашканда гариза бирүчеләрнең (эш бирүчеләрнең) хокукларын һәм бурычларын билгели торган халыкны эш белән тәэмин итү турындагы закон нигезләмәләре;

хезмәткә карата, хезмәт өлкәсендә мәҗбүри эшләтүне һәм дискриминацияне тыюга карата хокук билгели торган, эшче белән хезмәт килешүен төзегәндә эш бирүченең хокукларын һәм бурычларын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнарын, башка актларны бозган өчен җаваплылык билгели торган хезмәт законнары нигезләмәләре;

3) гариза бирүче (эш бирүче) белән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрында (вакансияләр банкында һәм эш бирүчеләрдә) хезмәткәрләргә ихтыяҗ, буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) булу турында белешмәләр бирү һәм урнаштыру, халыкның мәшгульлек үзәкләре тарафыннан җибәрелгән гражданнар белән әңгәмә нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү, гариза бирүчеләрнең (гражданнарның) эшкә бирелгән, аларны эшкә алу яки эшкә алуны кире кагу турында мәгълүмат күрсәтелгән юлламаларын рәсмиләштерү ысулын килештерү;

4) халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрына (вакансияләр һәм эш бирүчеләр банкына) гариза бирүче (эш бирүче) һәм буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр кертү;

5) физик затлар регистрында эш бирүчегә үзләренең шәхси мәгълүматларын тапшырырга ризалык биргән гражданнар турында белешмәләр булганда, хезмәткәрләргә ихтыяҗ турында белешмәләрдәге хезмәт функциясен (билгеле бер һөнәр (белгечлек) яки вазыйфа буенча эшне) үтәүгә таләпләрне, һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсенә, эш тәҗрибәсенә һәм күнекмәләргә карата таләпләрне исәпкә алып, гариза бирүчегә (эш бирүчегә) кирәкле хезмәткәрләрне сайлау;

6) гражданнарның кандидатураларын гариза бирүче (эш бирүче) белән килештерү;

7) гариза бирүчегә (эш бирүчегә) кирәкле хезмәткәрләр булмаганда, катнаш һөнәрләре (белгечлекләре) булган, яисә башка җирлектә яшәүче гражданнарның кандидатурасын тәкъдим итү;

8) гариза бирүчегә (эш бирүчегә), кирәкле хезмәткәрләрне мөстәкыйль сайлап алу өчен, гариза бирүче (эш бирүче) таләбенә туры килә торган хезмәткәр кандидатурасы (алга таба - гражданнар кандидатурасы исемлеге) турында белешмәләр тупланган физик затлар регистрындагы гражданнар кандидатурасы исемлеген тәкъдим итү;

9) гариза бирүчегә (эш бирүчегә) кирәкле хезмәткәрләр булмаганда түләүле иҗтимагый эшләр оештыруны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны, эш урыннары һәм укып эшләү урыннары ярминкәсендә катнашуны тәкъдим итү;

10) халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрына (вакансияләр һәм эш бирүчеләр банкына) административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү нәтиҗәләрен кертү.

3.5.2. Гариза бирүче (эш бирүче) турында һәм гариза бирүче (эш бирүче) тарафыннан тапшырылган документларда хезмәткәрләргә ихтыяҗ булуы турындагы белешмәләрне анализлау

Халыкның мәшгульлек үзәгенә почта, шул исәптән электрон почта, факсимиль элемтә аша яки электрон документ формасында, шул исәптән Бердәм портал яки Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып, гариза килгән очракта, яки гариза КФҮ, читтәге эш урыны аша тапшырылганда, мәшгульлек үзәге белгече гариза тапшырылган көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча, эш бирүче белән аны шәхсән кабул итүнең көнен, вакытын килештерә, шулай ук әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны тапшыру кирәклеге турында хәбәр итә.

Шәхси кабул итү барышында халыкның мәшгульлек үзәге белгече әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең булу-булмавын тикшерә.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчегә (эш бирүчегә) баш тарту өчен нигезләр булу турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кире кайтара.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта:

- гариза бирүченең (эш бирүченең) кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча дәүләт хезмәтеннән файдалану турында гаризасын (формасы 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыгы белән расланган) кабул итә (кирәк булган очракта тутыруда ярдәм итә);

- әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларның булу-булмавын тикшерә.

Гариза бирүче (эш бирүче) тарафыннан күрсәтелгән документлар нигезендә әлеге Регламентның 2.8 пунктында билгеләнгән сәбәпләр буенча дәүләт хезмәте күрсәтү яки аны күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту очрагында халыкның мәшгульлек үзәге белгече баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен аңлата, әлеге Регламентның 1 нче номерлы кушымтасына туры китерелгән формада 2 нөсхәдә язмача рәвештә баш тарту турында карар рәсмиләштерә, аның берсе халыкның мәшгульлек үзәгендә кала, икенчесе – гариза бирүчегә (эш бирүчегә) бирелә.

Үтәү вакыты: процедуралар 4 минут эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: документларны кабул итүдән баш тарту турында гариза бирүчегә бирелгән язмача хәбәрнамә һәм гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар, дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар яисә, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте

күрсәтүдән язмача баш тартуы.

3.5.3. Гариза бирүчегә (эш бирүчегә) халыкның мәшгульлеге турында закон нигезләмәләре хакында мәгълүмат бирү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчегә (эш бирүчегә) түбәндәгеләр турында хәбәр итә:

- дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гаризадагы белешмәләрнең, алар документлар нигезендә расланган (әлеге Регламентта каралган документлар тапшырылу) очракта, исәпкә алынуы турында;

- халыкны эш белән тәэмин итүдә катнашканда эш бирүчеләрнең хокукларын һәм бурычларын билгели торган, эш бирүчеләрнең хокуклары һәм бурычлары күрсәтелгән халыкны эш белән тәэмин итү хакындагы закон нигезләмәләре турында, хезмәткә карата, хезмәт өлкәсендә мәҗбүри эшләтүне һәм дискриминацияне тыюга карата хокук билгели торган, эшче белән хезмәт килешүен төзегәндә эш бирүченең хокукларын һәм бурычларын һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган хезмәт законнарын, башка актларны бозган өчен җаваплылык билгели торган хезмәт законнары нигезләмәләре турында.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 2 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (эш бирүчегә) хезмәт законнары нигезләмәләре турында хәбәр итү.

3.5.4. Гариза бирүче (эш бирүче) белән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрында (вакансияләр һәм эш бирүчеләр банкында) хезмәткәрләргә ихтыяҗ булуы турында белешмәләр бирү һәм урнаштыру, халыкның мәшгульлек үзәкләре тарафыннан җибәрелгән гражданнар белән әңгәмә нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү, гражданнарның эшкә бирелгән, аларны эшкә алу яки эшкә алуны кире кагу турында мәгълүмат күрсәтелгән юлламаларын рәсмиләштерү ысулын килештерү

Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрында (вакансияләр һәм эш бирүчеләр банкында) үзләре турында белешмәләр булган гариза бирүчеләргә (эш бирүчеләргә), 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 25 июнендәге 634 номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрдән файдалану өчен мөрәҗәгать иткәндә файдалану рөхсәт ителә торган электрон имза төрләре турында» карары нигезендә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән расланган, почта хезмәтеннән файдаланып җибәрелә ала торган, телефон аша элемтәгә кереп (алга таба мөрәҗәгатьне язмача раслаганда) әйтелә торган, факсимиль элемтә чараларын кулланып яки электрон документ рәвешендә, шул исәптән Бердәм портал яки Татарстан Республикасы порталын кулланып җибәрелә ала торган, хезмәткәрләргә ихтыяҗ булуы турында мәгълүмат бирү мөмкинлеге тәэмин ителә.

3.5.4.1. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүче (эш бирүче) белән:

- хезмәткәрләргә ихтыяҗ булуы турында мәгълүмат бирү (халыкның

мәшгульлек үзәгенә шәхсән бару, телефон, почта, шул исәптән электрон почта аша, факсимиль элемтә аша яки электрон документ формасында, шул исәптән Бердәм порталны яки Татарстан Республикасы порталын кулланып);

- хезмәткәрләргә ихтыяҗ булуы турында мәгълүмат урнаштыру (төбәк, төбәкара, федераль дәрәҗәләрдә, массакүләм мәгълүмат чараларында, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган башка мәшгульлек үзәкләренең Интернет-ресурсларында);

- халыкның мәшгульлек үзәкләре тарафыннан җибәрелгән гражданнар белән әңгәмә нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү, гражданнарның эшкә бирелгән, аларны эшкә алу яки эшкә алуны кире кагу турында мәгълүмат күрсәтелгән юлламаларын рәсмиләштерү (халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән бару, телефон, почта, шул исәптән электрон почта, факсимиль элемтә чаралары аша);

3.5.4.2. Гариза бирүче (эш бирүче) халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрына (вакансияләр һәм эш бирүчеләр банкына) хезмәткәрләргә ихтыяҗ булуы турында белешмәләр бирү һәм урнаштыру, халыкның мәшгульлек үзәкләре тарафыннан җибәрелгән гражданнар белән әңгәмә нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү, гражданнарның эшкә бирелгән, аларны эшкә алу яки эшкә алуны кире кагу турында мәгълүмат күрсәтелгән юлламаларын рәсмиләштерү ысулын сайлауны гамәлгә ашыра.

3.5.4.1, 3.5.4.2 пунктларда билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хезмәткәрләргә ихтыяҗ булуы турында белешмәләр бирү һәм урнаштыру, гражданнар белән әңгәмә нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү, гражданнарның эшкә бирелгән, аларны эшкә алу яки эшкә алуны кире кагу турында мәгълүмат күрсәтелгән юлламаларын рәсмиләштерү ысулын сайлау.

3.5.5. Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрына (вакансияләр һәм эш бирүчеләр банкына) гариза бирүче (эш бирүче) һәм буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр кертү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүче (эш бирүче) тарафыннан тапшырылган документлардагы белешмәләрне, исәпкә алу язуының теркәлү номерын беркетеп, халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучыларның электрон регистрына (вакансияләр һәм эш бирүчеләр банкына) кертү юлы белән гариза бирүчене (эш бирүчене) теркәүгә ала.

Әгәр гариза бирүче (эш бирүче) үзе тарафыннан мәгълүмат-аналитика системасында урнаштырылган вакансияләр турында мәгълүмат нигезендә мәгълүмат-аналитика системасыннан файдаланып халыкның мәшгульлек үзәгенә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен мөрәҗәгать итсә, гариза бирүче (эш бирүче) турында мәгълүмат, шулай ук хезмәткәрләргә ихтыяҗ булуы турында белешмәләр автомат режимда халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрына (вакансияләр һәм эш бирүчеләр банкына) килә.

Гариза бирүченең (эш бирүченең) мөрәҗәгате буенча гаризаны кабул итү көне һәм хисап язмасының теркәү номеры турында белешмәләр булган гариза күчермәсе бирелергә мөмкин.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 2 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрына (вакансияләр һәм эш бирүчеләр банкына) гариза бирүче (эш бирүче) һәм буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр кертү.

3.5.6. Физик затлар регистрында эш бирүчегә үзләренең шәхси мәгълүматларын тапшырырга ризалык биргән гражданнар турында белешмәләр булганда, хезмәткәрләргә ихтыяж турында белешмәләрдәге хезмәт функциясен (билгеле бер һөнәр (белгечлек) яки вазыйфа буенча эшне) үтәүгә таләпләрне, һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсенә, эш тәҗрибәсенә һәм күнекмәләргә карата таләпләрне исәпкә алып, гариза бирүчегә (эш бирүчегә) кирәкле хезмәткәрләрне сайлау

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчегә (эш бирүчегә) кирәкле хезмәткәрләр кандидатурасын сайлап алуны гамәлгә ашыра, эш бирүчегә үзләренең шәхси мәгълүматларын тапшырырга ризалык биргән гражданнарның шәхси мәгълүматлары булган исемлекне бастырып чыгара һәм аны гариза бирүчегә (эш бирүчегә) тәкъдим итә (физик затлар регистрында эш бирүче таләпләренә туры килә торган хезмәткәрләр кандидатурасы булганда).

Гариза бирүчегә (эш бирүчегә) кирәкле хезмәткәрләрне сайлау хезмәт функциясен (билгеле бер һөнәр (белгечлек), квалификация яки вазыйфа буенча эшне) үтәүгә таләпләрне, хезмәткәр кандидатурасына, аның һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсенә, эш тәҗрибәсенә һәм күнекмәләргә карата таләпләрне, шулай ук гражданнарның шәхси мәгълүматларын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 4 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүченең (эш бирүченең) гражданнарның шәхси мәгълүматларын үз эченә алган кирәкле хезмәткәрләрнең кандидатуралары исемлеген алуы, яисә гариза бирүчегә (эш бирүчегә) туры килә торган кандидатураларның булмавы турында хәбәр итү.

3.5.7. Гражданнарның кандидатураларын гариза бирүче (эш бирүче) белән килештерү

3.5.7.1. Гариза бирүче (эш бирүче) тәкъдим ителгән исемлектән кирәкле кандидатураларны сайлап ала һәм сайлап алынган кандидатураларны әңгәмәгә җибәрергә ризалыгын белдерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында гариза бирүчегә (эш бирүчегә) Интернет челтәрен кулланып телефон яки видеоэлемтә аша әңгәмә уздыру мөмкинлеге булдырыла.

3.5.7.2. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

- гариза бирүчегә (гражданинга) телефон аша буш эш урыны (вакантлы вазыйфа) һәм гариза бирүче (гражданин) белән әңгәмә уздырырга ризалык

биргән эш бирүче турында мәгълүмат җиткерә;

- гариза бирүчегә (эш бирүчегә) гариза бирүче (гражданин) белән әңгәмә нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү, гариза бирүчегә (гражданинга) бирелгән эшкә юлламаны рәсмиләштерү кирәклеге турында хәбәр итә.

3.5.7.1, 3.5.7.2 пунктларда билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң 3 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүченең (эш бирүченең) тәкъдим ителгән исемлектән кирәкле хезмәткәр кандидатурасын сайлап алуы

3.5.8. Гариза бирүчегә (эш бирүчегә) гражданнар кандидатурасы арасында кирәкле хезмәткәрләр булмаганда, катнаш һөнәрләргә (белгечлеккә) ия, яисә башка җирлектә яшәүче гражданнарның кандидатураларын тәкъдим итү

Кирәкле хезмәткәрләр булмаганда, мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчегә (эш бирүчегә) катнаш һөнәрләргә (белгечлеккә) ия, яисә башка җирлектә яшәүче гражданнарның кандидатураларын тәкъдим итә.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече, әлеге Регламентның 3.5.6 пунктында каралган гамәлләр эзлеклелегеннән чыгып, катнаш һөнәрләргә (белгечлеккә) ия, яисә башка җирлектә яшәүче хезмәткәрләрне сайлауны, гариза бирүче (эш бирүче) белән әлеге гражданнарның кандидатураларын килештерүне гамәлгә ашыра.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: катнаш һөнәргә ия хезмәткәр сайлау.

3.5.9. Гариза бирүчегә (эш бирүчегә), кирәкле хезмәткәрләрне мөстәкыйль сайлап алу өчен, гариза бирүче (эш бирүче) таләбенә туры килә торган хезмәткәр кандидатурасы турында белешмәләр тупланган физик затлар регистрындагы гражданнар кандидатурасы исемлеген тәкъдим итү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече физик затлар регистрында гариза бирүченең (эш бирүченең) таләпләренә туры килә торган хезмәткәрләр кандидатурасы булган очракта, эш бирүчегә үзләренең шәхси мәгълүматларын тапшырырга ризалык биргән гражданнарның шәхси мәгълүматларын үз эченә алган исемлекне бастырып чыгара һәм аны, хезмәткәрләрне мөстәкыйль сайлап алу өчен, гариза бирүчегә (эш бирүчегә) тәкъдим итә.

Гариза бирүчегә (эш бирүчегә) кирәкле хезмәткәрләрне сайлау хезмәт функциясен (билгеле бер һөнәр (белгечлек), квалификация яки вазыйфа буенча эшне) үтәүгә таләпләрне, хезмәткәр кандидатурасына, аның һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсенә, эш тәҗрибәсенә һәм күнекмәләргә карата таләпләрне, шулай ук гражданнарның шәхси мәгълүматларын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүченең (эш бирүченең) шәхси мәгълүматлар тупланган гражданнар кандидатурасы исемлеген алу.

3.5.10. Гариза бирүчегә (эш бирүчегә) кирәкле хезмәткәрләр булмаганда түләүле иҗтимагый эшләр оештыруны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны, эш урыннары һәм укып эшләү

урыннары ярминкәсендә катнашуны тәкъдим итү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече күрсәтелә торган дәүләт хезмәтенең эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү өлешендә гариза бирүчегә (эш бирүчегә) халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан оештырыла торган мәшгульлекнең актив сәясәте буенча түбәндәге чараларында:

- эш урыннары һәм укып эшләү урыннары ярминкәләрендә;

- түләүле җәмәгать эшләрендә;

- 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытта вакытлыча эшкә урнаштыруда;

- башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучылар арасыннан 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге беренче тапкыр эш эзләүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруда;

- эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруда катнашырга тәкъдим итә ала.

Гариза бирүче (эш бирүче) эш урыннары һәм укып эшләү урыннары ярминкәсендә катнашырга ризалыгын белдергәндә, халыкның мәшгульлек үзәге хезмәткәре гариза бирүчегә (эш бирүчегә) күрсәтелгән чараны үткәрү көне, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә.

Гариза бирүче (эш бирүче) халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан оештырыла торган мәшгульлекнең актив сәясәте чараларында катнашырга ризалыгын белдергәндә, мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчене (эш бирүчене) кирәкле мәгълүмат алу өчен мәшгульлекнең актив сәясәте чараларын оештыру эшләрен башкаручы белгечкә җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүченең (эш бирүченең) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнар тарафыннан оештырыла торган мәшгульлекнең актив сәясәте чараларында катнашу (түләүле җәмәгать эшләрен оештыру, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру, эш урыннары һәм эшләп уку урыннары ярминкәләрендә катнашу) турында тәкъдимнәр алуы.

3.5.11. Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрына (вакансияләр һәм эш бирүчеләр банкына) административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү нәтиҗәләрен кертү

Гариза бирүче (эш бирүче) халыкның мәшгульлек үзәге белгеченә буш эш урынында эшләү (вакантлы вазыйфаны башкару) өчен хезмәткәр кандидатурасын карау яки әңгәмә нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирә һәм гражданинны биш көнлек эшкә кабул иткән очракта, халыкның мәшгульлек үзәгенә эшкә алу көнен күрсәтеп, эшкә бирелгән юлламаны кире кайтара.

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрында (вакансияләр һәм эш бирүчеләр банкында) түбәндәгеләрне терки:

- гариза бирүчегә (эш бирүчегә) кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен (хезмәткәрләр

кандидатурасы турында белешмәләр булган исемлекне алу, эш урынын тутыру турында мәгълүмат кертү);

- гариза бирүчене (эш бирүчене) мәшгульлекнең актив сәясәте чараларында катнашу өчен җибәрү очрагын.

Үтәү вакыты: процедура мәгълүмат алынган көнне үтәлә.

Процедураның нәтиҗәсе: әңгәмә нәтиҗәсен теркәү яисә гариза бирүченең (эш бирүченең) буш эш урынында эшләү (вакантлы вазыйфаны башкару) өчен хезмәткәр кандидатурасын каравы.

3.6. Алга таба кабат мөрәҗәгать итүче гариза бирүчеләргә (эш бирүчеләргә) кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү

3.6.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәтенең алга таба кабат мөрәҗәгать итүче гариза бирүчеләргә (эш бирүчеләргә) кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү өлешендә түбәндәге административ гамәлләр башкарыла:

1) хезмәткәрләргә булган ихтыяҗ турында белешмәләрнең булу-булмавын тикшерү;

2) гариза бирүче (эш бирүче) тарафыннан түбәндәгеләр турында бирелә торган мәгълүмат белән танышу:

гражданнарның кандидатуралары исемлеген карау нәтиҗәләре;

халыкның мәшгульлек үзәгеннән юлланган гариза бирүчеләр (гражданнар) белән әңгәмә уздыру нәтиҗәләре;

түләнә торган җәмәгать эшләрен оештыруны хәл итү, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру, эш урыннары һәм укып эшләү урыннары ярминкәләрендә катнашу;

3) кирәкле хезмәткәрләрне сайлау критерийларын тәгаенләү;

4) хезмәткәрләргә булган ихтыяҗ турындагы мәгълүматларны халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрына (вакансияләр һәм эш бирүчеләр банкына) кертү;

5) әлеге Регламентның 3.5.1 пунктындагы 4 - 10 пунктчаларында каралган административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү.

3.6.2. Хезмәткәрләргә булган ихтыяҗ турында мәгълүматлар барлыгын тикшерү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

хезмәткәрләргә булган ихтыяҗ турында мәгълүматлар барлыгын тикшерә;

әлеге Регламентның 2.8 пунктында билгеләнгән нигезләргә туры китереп, дәүләт хезмәтен күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Хезмәткәрләргә булган ихтыяҗ турында мәгълүматлар гариза бирүче (эш бирүче) тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәгенә почта аша, электрон почтаны да кертеп, факсимиль элемтә ярдәмендә җибәрелергә мөмкин.

Хезмәткәрләргә булган ихтыяҗ турында мәгълүматлар халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан, алга таба аларны кәгазьдә раслау шарты белән, телефон аша кабул ителергә мөмкин.

Хезмәткәрләргә булган ихтыяҗ турында мәгълүмат ««Россиядә эш» гомумроссия эш урыннары базасы» мәгълүмати-аналитик системасында алдан урнаштырылган булырга мөмкин.

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту очрагында халыкның мәшгульлек үзәге белгече баш тарту сәбәпләрен, нигезләрен аңлата, әлеге Регламентның 1 нче номерлы кушымтасына туры китерелгән формада 2 нөсхәдә язмача рәвештә баш тарту турында карар рәсмиләштерә, аның берсе халыкның мәшгульлек үзәгендә кала, икенчесе – эш бирүчегә бирелә.

Үтәү вакыты: процедура 1 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү турында яисә халыкның мәшгульлек үзәгенең баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтүдән язмача баш тартуы турында карар.

3.6.3. Эш бирүче тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматлар белән танышу

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүче (эш бирүче) тарафыннан тәкъдим ителгән түбәндәгеләр турындагы мәгълүмат белән таныша:

гражданнарның кандидатуралары исемлеген карау нәтиҗәләре;

халыкның мәшгульлек үзәгеннән юллаган гражданнар белән әңгәмә уздыру нәтиҗәләре;

түләнә торган җәмәгать эшләрен оештыруны хәл итү, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру, эш урыннары һәм укып эшләү урыннары ярминкәләрендә катнашу.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүченең (эш бирүче) гражданнарның кандидатуралары исемлеген карау нәтиҗәләре, халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан җибәрелгән гражданнар белән әңгәмә нәтиҗәләре, түләүле җәмәгать эшләрен оештыруны хәл итү, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру, эш урыннары һәм укып эшләү урыннары ярминкәләрендә катнашу турында мәгълүматы белән танышу.

3.6.4. Кирәкле хезмәткәрләрне сайлау критерийларын ачыклау

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече, эш бирүче тәкъдим иткән документлардагы мәгълүматларны исәпкә алып, кирәкле хезмәткәрләрне сайлау критерийларына ачыклык кертә, гариза бирүче (эш бирүче) белән мәгълүмат алмашу ысулын, хезмәткәрләр кандидатурасын җибәрү тәртибен һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану очрагын раслау тәртибен килештерә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кирәкле хезмәткәрләрне сайлау критерийларын аныклау.

3.6.4.1. Хезмәткәрләргә булган ихтыяҗ турындагы мәгълүматларны халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрына (вакансияләр һәм эш бирүчеләр банкына) кертү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече хезмәткәрләргә булган ихтыяҗ турындагы мәгълүматларны халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрына (вакансияләр һәм эш бирүчеләр

банкына) кертә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучылар регистрына (вакансияләр һәм эш бирүчеләр банкына) гариза бирүче (эш бирүче) һәм буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр кертү.

3.6.5. Әлеге Регламентның 3.5.1 пунктындагы 5-10 пунктчаларында каралган административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчегә (эш бирүчегә) әлеге Регламентның 3.5.6 - 3.5.11 пунктларында билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге нигезендә кирәкле хезмәткәрләр кандидатурасын сайлый.

Үтәү вакыты: процедура гариза бирүче (эш бирүче) кабат мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе:

эш бирүчегә кирәкле хезмәткәрләрне сайлау;

гариза бирүчегә (эш бирүчегә) катнаш һөнәргә ия гражданнарның кандидатураларын тәкъдим итү;

гариза бирүчегә (эш бирүчегә) мәшгульлекнең актив сәясәте чараларында катнашуны тәкъдим итү.

3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм җибәрү, мәгълүматлар алу

3.7.1. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

- юридик затны (шәхси эшкуарны, крестьян (фермер) хуҗалыгын) дәүләт тарафыннан теркәүгә алу турында;

- Юридик затларның (Шәхси эшкуарларның) бердәм дәүләт реестрына кертү турында;

- чит ил юридик затларының аккредитацияләнгән филиалларының, вәкиллекләренең дәүләт реестрына тиешле язуны кертү турында;

- хосусый шәхси счетның иминият номеры;

организмының бозылган функцияләрен һәм яшәеш эшчәнлегендәге чикләмәләрен исәпкә алып, инвалидның киңәш ителә торган хезмәт һәм профессиональ эшчәнлек төрләрен сайлау өчен белешмәләр (ИПРАдан өземтә).

3.7.2. Гариза бирүче (эш бирүче) дәүләт теркәвенә алу турында таныклык (аккредитация һәм РФ Юстиция министрлыгы каршындагы Дәүләт теркәвенә алу палатасының дәүләт реестрына кертү турында таныклык – чит ил юридик затлары өчен) яки аның нотариаль яктан таныкланган күчермәсен тапшырмаган очракта, мөмкинлек булганда – электрон формада, халыкның мәшгульлек үзәге белгече электрон формада ведомствоара хезмәттәшлек системасы ярдәмендә белешмәләр тапшыру турында мөрәҗәгатьләр җибәрә:

- юридик затны (шәхси эшкуарны, крестьян (фермер) хуҗалыгын) дәүләт тарафыннан теркәүгә алу турында белешмәләрне Юридик затларның (Шәхси эшкуарларның) бердәм дәүләт реестрына кертү турында;

- чит ил юридик затларының аккредитацияләнгән филиалларының, вәкиллекләренең дәүләт реестрына тиешле язуны кертү турында.

Гариза бирүче (гражданин) шәхси (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, шул исәптән электрон документ рәвешендәгесен дә тапшырмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша хосусый шәхси счетның иминият номеры турында мәгълүмат кирәклеге хакында электрон рәвештә мөрәҗәгать юллый.

3.7.1 һәм 3.7.2 пунктларда билгеләнә торган процедуралар гариза килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган белешмәләр, мәгълүматлар бирү турында мөрәҗәгатьләр.

3.8. Гариза бирүчеләргә электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү.

3.8.1. Дәүләт хезмәтеннән файдалануга гариза тапшырудан тыш, дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелми.

Электрон документ формасындагы гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләрен кулланып җибәрелергә, шулай ук халыкның мәшгульлек үзәгенә гариза бирүче тарафыннан электрон мәгълүмат саклагычларда тапшырылырга мөмкин.

Гариза электрон формада, шул исәптән халыкның мәшгульлек үзәге рәсми сайты, Татарстан Республикасы Порталы, Бердәм портал аша җибәрелгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гаризаны кәгазьдә бастырып чыгара һәм аны кабул итеп алынган көндә дәүләт хезмәтләре күрсәтү турында гаризаларны теркәү журналында терки.

Гариза электрон формада эшләми торган вакытта килгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гаризаны килгән көненнән соң килә торган беренче эш көнендә кәгазьдә бастырып чыгара һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү турында гаризаларны теркәү журналында терки.

3.9. Техник хаталарны төзәтү

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 2 нче номерлы кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.

3.9.1. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның (гариза бирүчеләрнең) мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында (3 нче номерлы кушымта) терки;

- кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алу, эшкә җибәрү өчен гражданнар кандидатуралары исемлеген яисә эш вариантлары исемлеген, яисә халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимне яңадан рәсмиләштерә, яисә баланы өч яшькә җиткәнче караган өчен отпуск вакытында хатын-кызларга мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри укулар узарга тәкъдим итә;

- кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алу, эшкә җибәрү өчен гражданнар кандидатуралары исемлеген яисә эш вариантлары исемлеген, яисә халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимне, яисә баланы өч яшькә җиткәнче караган өчен отпуск вакытында хатын-кызларга мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри укулар узу турында тәкъдимне яңадан рәсмиләштерү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән гариза бирүчегә хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: - техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, үзгәртеп рәсмиләштерелгән кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алу, эшкә җибәрү өчен гражданнар кандидатуралары исемлеге яисә эш вариантлары исемлеге, яисә халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән тәкъдим, яисә баланы өч яшькә җиткәнче караган өчен отпуск вакытында хатын-кызларга мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри укулар узу турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән тәкъдим.

## 4. Дәүләт хезмәтләре күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә агымдагы контрольне халыкның мәшгульлек үзәге директоры яки аның вәкаләтле хезмәткәре башкара.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне агымдагы тикшерүдә тоту халыкның мәшгульлек хезмәте белгеченең әлеге Административ регламентны, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2010 елның 8 ноябрендәге 972н номерлы боерыгы белән расланган Халыкның мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы затлар (физик затлар һәм эш бирүчеләр) регистрын, аларда булган белешмәләрне бир тәртибен, срокларын һәм формасын да кертеп, алып бару тәртибен, гариза бирүчеләрне исәпкә алу документациясе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү эшчәнлеген регламентлаучы башка документларның бланкларын тутыруга, алып баруга һәм саклауга карата таләпләрне саклавына һәм үтәвенә тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшерүләрне гамәлгә ашыру ешлыгы халыкның мәшгульлек үзәге директоры тарафыннан билгеләнә.

4.3. Халыкның мәшгульлегенә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт гарантияләренең тәэмин ителүен тикшерүдә тотуны, эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү өлешендәге дәүләт гарантияләреннән тыш, халыкның мәшгульлегенә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт гарантияләренең тәэмин ителүенә күзәтчелек һәм контроль буенча вәкаләтләрне үтәү кысаларында Министрлык гамәлгә ашыра.

Халыкның мәшгульлегенә булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт гарантияләренең тәэмин ителүен тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан планлы (планнан тыш) урынга чыгып (документар) тикшерүләр уздыру юлы

белән гамәлгә ашырыла.

4.4. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.5. Гариза бирүчеләр (гражданнар), аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә халыкның мәшгульлек үзәге эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр судка кадәр тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи заты (белгече) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка тапшырыла.

КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮ җитәкчесенә белдерелә, КФҮ җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата – КФҮ гамәлгә куючыга.

5.2. Гариза бирүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

- дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү срогы бозылганда;
- дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;
- гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;
- дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;
- дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

- дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

- дәүләт хезмәте күрсәтүче халыкның мәшгульлек үзәге, дәүләт хезмәте күрсәтүче халыкның мәшгульлек үзәге вазыйфаи заты (белгече) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

- дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чорлары яисә тәртибе бозылганда;

- дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

- дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны гариза бирүчедән таләп иткәндә.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яки дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение), шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган вазыйфаи заты (белгече) яисә дәүләт хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм порталдан (https://www.gosuslugi.ru) файдаланып җибәрелә ала, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» челтәреннән файдаланып, КФҮ (http://mfcl6.tatarstan.ru) рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Бердәм порталдан (http://www.gosuslugi.ru) җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең), шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яки дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны

төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

- карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органда вазыйфаи затның (белгечнең) яисә граждан хезмәткәренең, КФҮ, аның җитәкчесенең яки хезмәткәренең исеме;

- гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, гариза бирүче – юридик затның атамасы урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

- дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яки дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

- гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

Халыкның мәшгульлек үзәге, шулай ук аның вазыйфаи затлары карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

- шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, гариза бирүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

- шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.7. Карарны кабул иткән көннән соң бер көн узганчы гариза бирүчегә (гражданинга) язмача яисә гариза бирүче (гражданин) ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта гариза бирүчегә (гражданинга) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение), КФҮ тарафыннан гамәлгә ашырыла торган

гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба гражданинга эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат (халыкның мәшгульлек үзәге белгече) булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.».

## 6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

6.1. Гариза бирүче КФҮ мөрәҗәгать иткәндә гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында гариза бирүчегә хәбәр итү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) халыкның мәшгульлек үзәгенә гаризаны җибәрү.

6.2. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү.

Гариза бирүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен КФҮ шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ белгече гариза бирүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны КФҮнең http ://mfc16.tatarstan.ru/ сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алуның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

6.3.1. Гариза бирүче шәхсән яисә ышанычлы заты аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә КФҮ, КФҮнең читтән торып эшләү урынына тапшыра.

6.3.2. КФҮнең гаризалар кабул итә торган белгече КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар КФҮ эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.4. халыкның мәшгульлек үзәгенә гаризаны җибәрү.

6.4.2. КФҮ белгече гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә халыкның мәшгульлек үзәге һәм КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибе - халыкның мәшгульлек үзәге һәм КФҮ арасында төзелә торган хезмәттәшлек турында килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлек итү тәртибе КФҮ эш регламенты белән җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮнең эш регламентында, халыкның мәшгульлек үзәге белән КФҮ арасындагы үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны КФҮдә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – халыкның мәшгульлек үзәгенә юлланган гариза.

6.5. Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү.

6.5.1. Халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан бирелгән бәяләмәдә хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турындагы гаризаны гариза бирүче шәхсән яки ышанычлы заты аша КФҮгә язмача тапшыра.

КФҮнең гаризалар кабул итә торган белгече КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар КФҮнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.6. Халыкның мәшгульлек үзәгенә техник хаталарны төзәтү турында гариза җибәрү.

6.6.2. КФҮ белгече халыкның мәшгульлек үзәге һәм КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, әмма гаризаны КФҮдә теркәгән көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрә.

Гражданнарга туры килә торган
эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә
кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда
булышлык күрсәтү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 1
нче кушымта

үрнәк

«__________________ халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе

Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә,ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында 20___ елның «__» __________ № _____

КАРАР

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 20___ елның «__»___________ ___ номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының 2.8 пункты нигезендә гражданин (эшкә алучы зат) ________________________________________ гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән БАШ ТАРТЫРГА.

Баш тарту сәбәбе:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече ____________________________________

(ФИА, имза)

Карарны алдым

______________________________________________________________________

(Гражданинның, эш бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

«__» ____________ 20__ ел.

Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

үрнәк

«__________________ халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенә

Техник хата төзәтү турында гариза

Мин,______________________________________________________________
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) тулысынча күрсәтелә),
яши торган адресы: ______________________________________________

____________________________________________________________________,
(гариза бирүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)

____________________________________________________________________
(гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документның аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы, документны биргән органның аталышы)

20___ елның «___»___________________ бирелгән,
кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алу, эшкә җибәрү өчен гражданнар кандидатуралары исемлегендә яисә эш вариантлары исемлегендә, яисә халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимдә, яисә баланы өч яшькә җиткәнче караган өчен отпуск вакытында хатын-кызларга мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри укулар узу өчен тәкъдимдә (кирәклесенең астына сызарга) җибәрелгән, техник хатаны төзәтүегез турында үтенәм

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
____________________________________________________________.

Яңадан рәсмиләштерелгән кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алу, эшкә җибәрү өчен гражданнар кандидатуралары исемлеген яисә эш вариантлары исемлеген, яисә халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башка дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы яңадан рәсмиләштерелгән тәкъдимне, яисә баланы өч яшькә җиткәнче караган өчен отпуск вакытында хатын-кызларга мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри укулар узу турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән тәкъдимне алырга риза

____________________________________________________________________
(язмача, телефон буенча, смс-хәбәр белән, электрон почта аша, ТР Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетка)

«__»____________20__ел.________________________ ________________________
(гариза бирүченең имзасы) (тулы имза)

Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Гражданнарның (эшкә алучы затларның) мөрәҗәгатьләрен теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Мөрәҗәгать итү датасы | Гражданинның ФИА | Адресы | Мөрәҗәгать итү сәбәпләре | Мөрәҗәгать нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәтә күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

## 1. Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре

| т/с | Халыкның мәшгульлек үзәгенең аталышы | Вазыйфа | Телефон | Урнашкан урын адресы, электрон адресы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | «Азнакай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85592) 7-57-90 | 423330, Азнакай шәһәре, Төзүчеләр урамы, 10 Czn.Aznakaevo@tatar.ru |
| 2 | «Аксубай районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84344) 2-73-94 | 423060, Аксубай ш.т.п., Романов урамы, 6 Czn.Aksubaevo@tatar.ru |
| 3 | «Актаныш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-85552) 3-09-83 | 423740, Актаныш районы, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 61 Czn.Aktanysh@tatar.ru |
| 4 | «Алексеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84341) 2-54-00 | 422900, Алексеевск эшчеләр поселогы, Ленин урамы, 87 Czn.Alekseevskoe@tatar.ru |
| 5 | «Әлки районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84346) 2-15-89 | 422870, Базарлы Матак авылы, Совет урамы, 8 Czn.Alkeevo@tatar.ru |
| 6 | «Әлмәт шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8553) 32-45-47 | 423452, Әлмәт шәһәре, Герцен урамы, 86а Czn.Almet@tatar.ru |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7 | «Апас районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84376) 2-12-15 | 422350, Апас авылы, Шоссейная урамы, 5 Czn.Apastovo@tatar.ru |
| 8 | «Арча районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84366) 3-17-33 | 422000, Арча ш.т.п., Банк урамы, 6в Centr.Arskiy@tatar.ru |
| 9 | «Әтнә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84369) 2-16-51 | 422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы, 63 Czn.Atnya@tatar.ru |
| 10 | «Баулы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85569) 5-62-29 | 423930, Баулы шәһәре, Энгельс урамы, 56 Czn.Bavly@tatar.ru |
| 11 | «Балтач районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84368) 2-44-19 | 422250, Балтач ш.т.п., Совет урамы, 16 Czn.Baltasi@tatar.ru |
| 12 | «Бөгелмә шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85594) 4-17-60 | 423230, Бөгелмә шәһәре, Октябрь урамы, 15 Czn.Bugulma@tatar.ru |
| 13 | «Буа шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84374) 3-13-73 | 422430, Буа шәһәре, Р.Люксембург урамы, 157/1 Czn.Buinsk@tatar.ru |
| 14 | «Югары Ослан районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-84379) 2-24-28 | 422570, Югары Ослан районы, Югары Ослан авылы, Медгородок урамы, 21 а Czn.V-uslon@tatar.ru |
| 15 | «Биектау районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84365) 2-16-17 | 422700, Биектау авылы, Центральная урамы, 7 CZN.VGora@tatar.ru |
| 16 | «Чүпрәле районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-84375) 2-24-51 | 422470, Иске Чүпрәле авылы, Центральная урамы, 15 Czn.Drozhzhanoe@tatar.ru |
| 17 | «Алабуга шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85557) 7-58-58 | 423600, Алабуга шәһәре, Спас урамы, 5 Czn.Elabugi@tatar.ru |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 18 | «Зәй шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85558) 7-15-43 | 423520, Зәй шәһәре, Нефтьчеләр проспекты, 37б Czn.Zainsk@tatar.ru |
| 19 | «Зеленодольск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84371) 5-64-90 | 422550, Зеленодольск шәһәре, Татарстан урамы, 1 Czn.Zdol@tatar.ru |
| 20 | «Кайбыч районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84370) 2-12-60 | 422330, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 Czn.Kaibicy@tatar.ru |
| 21 | «Кукмара районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84364) 2-67-54 | 422110, Кукмара шәһәре, Ворошилов урамы, 44 Czn.Kukmor@tatar.ru |
| 22 | «Лаеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-84378) 2-44-54 | 422610, Лаеш шәһәре, Чернышевский урамы, 23 Laish.Czn@tatar.ru |
| 23 | «Лениногорск шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85595) 5-59-70 | 423250, Лениногорск шәһәре, Гагарин урамы, 51 Czn.Leninogorsk@tatar.ru |
| 24 | «Мамадыш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-85563) 3-35-57 | 422190, Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы, 12 Czn.Mamadysh@tatar.ru |
| 25 | «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Менделеевск районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Әгерҗе районы филиалы | директор | (85549) 2-23-57<br><br>(85551) 2-31-73 | 423650, Менделеевск шәһәре, Фомин урамы, 19 Czn.Men@tatar.ru; 422230, Әгерҗе шәһәре, К.Маркс урамы, 11а Centr.Agryzskiy@tatar.ru |
| 26 | «Минзәлә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-85555) 3-23-80 | 423700, Минзәлә шәһәре, Ленин урамы, 80 Czn.Menzelinsk@tatar.ru |
| 27 | «Мөслим районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85556) 2-57-37 | 423970, Мөслим авылы, Пушкин урамы, 47 Czn.Muslymovo@tatar.ru |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 28 | «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Яр Чаллы шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Тукай районы филиалы | директор | (8552) 52-42-68<br>(8552) 52-96-97 | 423831, Яр Чаллы шәһәре, Сөембикә проспекты, 47 Chelny.CZN@tatar.ru; 423831, Яр Чаллы шәһәре, Сөембикә проспекты, 47 Czn.Tukaev@tatar.ru |
| 29 | «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Кама Аланы бүлеге | директор | (8555) 42-40-79 (8555) 33-98-61 | 423570, Түбән Кама шәһәре, Бызов урамы, 20а Czn.Nk@tatar.ru 423564, Түбән Кама районы, Кама Аланы эшчеләр поселогы, 2/01 Czn.Nk@tatar.ru |
| 30 | «Яңа Чишмә районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-84348) 2-23-43 | 423190, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Ленин урамы, 93 Czn.Novoshesh@tatar.ru |
| 31 | «Нурлат ш. халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84345) 2-46-30 | 423040, Нурлат шәһәре, Р.С.Хәммәдиев урамы, 19 Czn.Nurlat@tatar.ru |
| 32 | «Питрәч районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84367) 3-04-84 | 422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 34 CentrZan.Pestr@tatar.ru |
| 333 | «Балык Бистәсе районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84361) 2-21-81 | 422650, Балык Бистәсе ш.т.п., Ленин урамы, 48 Czn.R.sloboda@tatar.ru |
| 34 | «Саба районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-84362) 2-28-15 | 422060, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.п., З.Йосыпов урамы, 7 SZN.Saby@tatar.ru |
| 35 | «Сарман районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (85559) 2-42-62 | 423350, Сарман авылы, Ленин урамы, 26 Czn.Sarmanovo@tatar.ru |
| 36 | «Спас районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84347) 3-07-72 | 422820, Болгар шәһәре, Хирург Шеронов урамы, 21 Czn.Bolgar@tatar.ru |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 37 | «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Кама Тамагы районы филиалы | директор | (84373) 2-63-29<br><br>(8-84377) 2-14-67 | 422370, Тәтеш шәһәре, Ирек мәйданы урамы, 45 Czn.Tetyushi@tatar.ru; 422820, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы ш.т.п., К. Маркс урамы, 2а Filial.K-uste@tatar.ru |
| 38 | «Теләче районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84360) 2-13-51 | 422080, Теләче авылы, Ленин урамы, 73 Czn.Tyulyachi@tatar.ru |
| 39 | «Чирмешән районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84396) 2-54-59 | 423100, Чирмешән авылы, Титов урамы, 5 Czn.Cheremshan@tatar.ru |
| 40 | «Чистай шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (84342) 5-13-34 | 422980, Чистай шәһәре, К.Маркс урамы, 35 Czn.chist@tatar.ru |
| 41 | «Ютазы районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (8-85593) 2-60-18 | 423950, Урыссу ш.т.п., Пушкин урамы, 105/1 Czn.Yutazy@tatar.ru |
| 42 | «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм «Казан шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Совет районы филиалы | директор | (843) 562-48-33 (843) 273-85-03 | 420034, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 81а Czn.g_Kazan@tatar.ru; 420029, Казан шәһәре, Журналистлар урамы, 13а CZN/Sovetskiy@tatar.ru |
| 43 | «Авиатөзелеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 537-86-00 | 420085, Казан шәһәре, 1 нче Муром урамы, 33а Czn.Avia@tatar.ru |
| 44 | «Вахитов районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 277-51-59 | 420049, Казан шәһәре, Качалов урамы, 77 Czn.Vah@tatar.ru |
| 45 | «Киров районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 554-77-36 | 420032, Казан шәһәре, Слободская урамы, 23 czn.kirovskiy@tatar.ru |
| 46 | «Мәскәү районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт | директор | (843) 543-47-72 | 420039, Казан шәһәре, Гагарин урамы, 46 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | казна учреждениесе | | | czn.moskovski@tatar.ru |
| 47 | «Яңа Савин районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 543-19-52 | 420044, Казан шәһәре, Ибраһимов проспекты, 41 Czn.Novosavin@tatar.ru |
| 48 | «Идел буе районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе | директор | (843) 224-86-83 | 420101, Казан шәһәре, Бертуган Касыймовлар урамы, 22/7 CZN.Privol@tatar.ru |

## 2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа атылышы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-03 | Klara.Tazetdinova@tatar.ru |
| Социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары булдыру бүлеге башлыгы | 557-20-73 | Elena.Kibardina@tatar.ru |
| Хезмәт миграциясе һәм эш бирүчеләр белән үзара хезмәттәшлек бүлеге башлыгы | 557-21-58 | Azat.Ayupov@tatar.ru |